СИШӘМБЕ
9 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 7 (5807)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ПРОПАГАНДА ЭШЕН БҮГЕНГЕ ТАЛӘПЛӘР ЮГАРЫЛЫГЫНА

Пропаганда һәм агитация работникларының шушы көннәрдә булып үткән өлкә киңәшмәсе партия пропагандасын үзгәртеп кору эшенә йомгак ясады. ВКП(б) Үзәк Комитетының пропаганда турындагы карары нигезендә партия пропагандасын үзгәртеп кору эшендә ВКП(б) ның Татарстан оешмасы шактый зур уңышларга иреште.

Партияле һәм партиясез большевиклардан меңнәрчә, ун меңнәрчә иптәшләр марксизм-ленинизм теориясен үзләштерү өстендә тырышып эшләүләре нәтиҗәсендә, идея-политик яктан бик нык үстеләр, дәүләт һәм җәмагат эшләренә тагын да активрак катнаша башладылар. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар кампаниясе вактында бу бик ачык күренде.

Партия пропагандасының төрле формаларын куллану марксизм-ленинизм теориясен үзлекләреннән өйрәнүчеләргә гаять зур ярдәм итте. Бу өлкәдә лекцияләрнең роле аеруча зур булды. Бер елдан артык в кыт эчендә 3 меңнән артык лекция укылуы һәм аларны 350 меңнән артык кеше тыңлавы моның ачык мисале булып торалар. Лекцияләрнең сыйфаты да шактый яхшырды. Марксизм-ленинизм пропагандасының көчле коралы булган большевистик матбугат өлкәсендә дә күп кенә эшләр эшләнде. Елдан артык вакыт эчендә өлкә газеталары һәм „Татарстан большевигы“ журналы битләрендә ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә 350 дән артык теоретик мәкаләләр, консультацияләр, лекцияләрнең бирелүе; пропаганда эшенең куелышы турында, тәҗрибәләрне уртаклашу буенча күп санда мәкалә һәм хәбәрләрнең урнаштырылуы; газеталарыбызның пропаганда эшенең уңышлы тәҗрибәләрен яктырткан аерым битләр оештырулары—болар барсы да, һич шиксез, уңышлы якларны күрсәткән фактлар.

Хәзер инде безнең Татарстанда „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның VII, VIII, IX бүлекләрен конспект төзеп өйрәнүче иптәшләр аз түгел, ә күп кенә иптәшләр „Кыскача курс“ны өйрәнү эшен тәмам итеп, хәзерге вакытта марксизм-ленинизм классикларының аерым әсәрләрен ныклап өйрәнү өстендә эшлиләр.

Мәсәлән, Минзәлә Педагогия училищесенең укытучысы иптәш Майоров Маркс, Энгельс әсәрләреннән—„Коммунистик манифест“, „Табигат диалектикасы“, „Людвиг Фейербах“, „Луи Банапартның унсигезенче брюмеры“, „Франциядә 1848 нче елгы революция“; В. И. Лениннең—„Бер адым алга, ике адым артка“, „Нәрсә эшләргә?“, „Буржуаз-демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы“; иптәш Сталинның—„Ленинизм мәсьәләләре“, „Марксизм һәм милли-колониаль мәсьәлә“ дигән әсәрләрен җентекләп укып чыккан. „Правда“ колхозы (Калинин районы) янындагы партоешма секретаре Мәҗитев, шул ук колхозның председателе Хәйруллин иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның барлык бүлекләрен өйрәнеп, хәзер В. И. Ленин һәм иптәш Сталинның аерым әсәрләрен өйрәнү өстендә эшлиләр. Мондый иптәшләр хәзер безнең республикабызда аз түгел, аларның саны көннән-көн арта бара. Пропаганда һәм агитация кебек мактаулы һәм җаваплы эшне башкару өлкәсендәге кадрларның үсеше дә — бу тармактагы эшебезнең зур уңышларыннан берсе булып тора. Безнең күп кенә пропагандистларыбыз бу мактаулы эшне намус белән үтиләр.

Партия пропагандасы өлкәсендә шактый зур уңышлар булу белән бергә, күп кенә кимчелекләр дә бар әле. Аларның хәзерге көндә иң зурысы — марксизм-ленинизм теориясен өйрәнү эшенә күп кенә җитәкче работникларның әле дә ныклап керешмәүләрендә. „Кыскача курс“ чыгуга 15—16 ай вакыт үтүгә карамастан, күп кенә җитәкче работниклар шушывакытка кадәр аның бары тик I-II бүлекләрен генә өйрәнәләр. Мисаль өчен „Строитель“ комбинаты директоры Игнатов, Наркомзем Черзор, Җитен комбинаты директоры Косалапов, ВКП(б)ның Кызыл Армия райкомы секретаре Хәлиуллин, ВКП(б) ның Биләр райкомы секретаре Вафин, ВКП(б) ның Тәтеш райкомы пропагандисты Николаев иптәшләрне алырга кирәк. Бу иптәшләр үзләренең теоретик артталыкларын бетерү өстендә эшләү өчен „вакыт“ таба алмыйлар.

Маглүм ки, җитәкче работниклар үзләренең теоретик дәрәҗәләрен күтәрү өстендә тиешенчә эшләмәгән партоешмаларда пропаганда эшенең куелышы да канәгатләнерлек түгел. Киресенчә, җитәкче работниклар үзләре үрнәк күрсәткән партоешмаларда пропаганда эше яхшы бара.

Менә Калинин, Киров (Казан), Минзәлә, Мамадыш районнары. Бу районнарда пропаганда эше шактый яхшы куелган. Чөнки ВКП(б) райкомнары секретарьлары марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүдә башкаларга үзләре үрнәк күрсәтәләр, пропаганда эшенә конкрет җитәкчелек итәләр.

Партия пропагандасы эшендә лекцияләрнең роле гаять зур. Шунлыктан, пропаганданың бу тармагына аеруча игтибар бирелергә тиеш. Ләкин бу өлкәдә, лекцияләрне оештыруда һәм сыйфат якларына контрольлек итүдә җидди кимчелекләр бар әле. Моңа кадәр булган лекцияләрнең, газеталарда урнаштырылган теоретик мәкаләләрнең, консультацияләрнең күбесе диярлек ВКП(б) тарихының Октябрьгә кадәр булган чорына карата булдылар. ВКП(б) тарихының Октябрьдән соңгы чорын өйрәнү мәсьәләсенә зур әһәмият бирелергә тиеш. Марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүдә төп метод, һич шиксез, үзлегеңнән өйрәнү методы. Ләкин бу әле ВКП(б) тарихын түгәрәкләргә йөреп өйрәнү эшен үз агымына куярга ярый дигән сүз түгел. ВКП(б) ның Красный Бор, Кузнечиха, Сарман, Беренче Май, Алексеевск, Столбище һәм Югары Ослан райкомнары түгәрәкләргә җитәкчелек итү эшен үз агымына куйганнар. Бу районнарда күп кенә түгәрәкләрнең составы политик һәм гомуми белем ягыннан бик чуар, занятиеләргә йөреш түбән, дисциплина йомшак, занятиеләр иске метод—сорауларга җавап бирү методы белән үткәреләләр, иптәшләрчә дискуссияләр юк, мәсьәләләр җентекләп тикшерелмиләр.

Парткабинетлар эшендә дә җидди кимчелекләр бар. Күп кенә парткабинетлар групповой һәм индивидуаль консультацияләрне оештыруга, бигрәк тә урыннарга барып оештыруга игтибар биреп җиткермиләр, тиешенчә инициатива күрсәтмиләр. Лекцияләр, консультацияләр, теоретик беседалар, ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләрнең тәҗрибәләрен уртаклашу киңәшмәләре оештыру кебек эшләрдә дә парткабинетлар үзләренең инициативаларын арттырасылары бар әле.

Пропаганда өлкәсендә булган кимчелекләрне тиз вакыт эчендә бетереп, кадрларыбызны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыру эшен үрнәк итеп оештырырга, партиябезнең Үзәк Комитеты кушканча, юлбашчыбыз иптәш Сталин кушканча оештырырга тиешбез. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар, барлык шартлар тудырылган.

БОЗЛАР АРАСЫНДА ХӘРӘКӘТ ИТҮЧЕ КАРАБНЫҢ РАДИОСЫ

Советлар Союзы Герое иптәш Э. Т. Кренкель белән беседа

Котыпны тикшерү тарихы, Арктиканы кыю буйсындыручыларның тышкы дөньядан аерылганда һәм аның белән һәр төрле элемтәдән мәхрүм булганда, рәхимсез төньяк табигатенең мәкерле стихиясе алдында үзләренең ярдәмсез калуларын хис итеп һәлак булулары кебек бик күп вакыйгаларне белә. „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының экипажы, туган ярлардан еракта 26 ай буе дәвам иткән бөтен хәрәкәт вактында, бу куркынычлы хисне—барлык башка дөньядан аерылу хисен бер кайчан да кичермәде.

Чиксез океанда бозлар теләге белән хәрәкәт итүче экипажны җир белән, туганнары, дуслары һәм якыннары белән радио элемтәдә тотты. Бозлар арасындагы тиңдәшсез хәрәкәтнең уңышлы төгәлләнүе, бозлар арасында хәрәкәт итүче караб белән материк арасында радио аркылы нормаль элемтә тотуга күп яклардан бәйле булды дип, ышаныч белән әйтергә мөмкин.

„Седов“ның радио элемтәсе кыен сынауны бик яхшы үтте. Ул бик яхшы һәм өзлексез эшләде. Материк белән элемтә тоту бер генә көнгә дә өзелмәде.

Седовчыларның яхшы гына җиһазландырылган тапшыру станциясе бар, ул теләсә нинди дулкыннарда эшләде. Ул 0,5 киловатт, 0,07 киловатт һәм 0,06 киловатт куәтле төп өч передатчиклардан һәм 0,2 киловатт көчендәге чаткылы бер авария передатчигыннан тора. Ягулык чикләнгән санда булганлыктан, элемтә, башлыча, аз куәтле передатчиклар аркылы тотылды, бу хәл эшнең эффектын аз гына да киметмәде. Карабта, болардан тыш, озын дулкында һәм кыска дулкында эшли торган ике приемник бар. Бу радио җиһазлары барсы да Ленинградтагы радио заводларының бирсендә, 1935 һәм 1936 нчы елларда, бөтенләе белән совет материалларыннан эшләнгәннәр.

Бозлар арасында хәрәкәт итүче карабтагы радио станциянең эш күләмен түбәндәгеләр буенча гына да күз алдына китерергә мөмкин: хәрәкәт вактында ул йөз меңнәрчә сүз тапшырды һәм кабул итте. Узган елның май аеннан бирле „Седов“ ның радио станциясе тәүлегенә уртача 11 сәгать эшләде. „Седов“ бозваткыч пароходы радио станциясенең чакыру сигналы—„УНАД“ материкта һәм бигрәк тә аның төньяк ярларында бик яхшы билгеле.

Бозлар арасында хәрәкәт башланганда „Седов“ ның радистлары телеграммаларны тапшыру пунктлары аркылы—Тикси бухтасындагы һәм Шалауров мысындагы (Ляхов атаулары) котып станцияләренең рацияләре аркылы бирделәр. Караб көнбатышка таба барган саен, Челюскин мысындагы, Рудольф атавындагы, Желание мысындагы, Амдермдагы радио станцияләр һәм Диксон атавындагы радиоцентр седовчылар белән радио буенча регуляр элемтә тоттылар.

Седовчылар радио буенча нәрсәләр тапшырдылар һәм нәрсәләр кабул иттеләр?

Бозлар арасында хәрәкәт итә торган карабтан һәр көнне, тәүлеккә дүрт тапкыр материкка метеорология сводкалары бирелеп торды. Һава карталары төзү өчен синоптиклар алардан һәр көнне файдаландылар. Седовчылар үзләренең фәнни күзәтүләре турында Зур Җиргә радио буенча тәртипле рәвештә белешмәләр җибәреп тордылар. „Седов“ ның радио станциясе совет матбугаты өчен системалы рәвештә хәбәрләр тапшырып торды.

Карабтагы седовчыларга материктан һәр көнне Главсевморпутьның радио бюллетене, СССР дагы тормыш турында һәм халыкара вакыйгалар турында хәбәрләр, лекцияләр, докладлар тапшырылып торды. Батыр моряклар өчен Москвадан еш кына бик яхшы концертлар тапшырылдылар. Арктика геройлары радио аша үзләренең туганнарының һәм якыннарының тавышларын ишеттеләр. Радио аларга Сталин, Молотов һәм Калинин иптәшләрнең рухландыручы котлау сүзләрен китерде.

„Седов“ ның радистлары—Александр Александрович Полянский һәм Николай Михайлович Бекасов иптәшләр үз-үзләрен аямыйча эшләделәр. „Седов“ ның капитаны иптәш Бадигин өлкән радист Полянский турында болай ди: „Бик яхшы котыпчы. Үз эшен бик яхшы белә. Элемтә буенча бөтен эшне төгәл һәм өзлексез алып бара. Хезмәткә сәләтле булуы белән аерылып тора. Бер нинди хәлләрдә дә каушап калмый. Стахановчы. Седовчылар коллективында гаять зур хөрмәт һәм мәхәббәт казанды“. Бекасов турында да иптәш Бадигин шундый ук бик яхшы отзыв бирә.

Соңгы көннәрдә уннарча радио станцияләр „Иосиф Сталин“ бозваткычы һәм „Седов“ белән ышанычлы һәм өзлексез элемтә тоталар. Героик карабны бозлар тоткынлыгыннан коткару көннәрендә радио аркылы сөйләшүләр тәүлегенә 10.000 сүзгә кадәр җитә. Бу көннәрдә безнең радио станцияләребезнең бик яхшы эшләүләрен түбәндәге факт ачык күрсәтеп тора. „Иосиф Сталин“ бозваткычы радистының, седовчылар флагман карабының прожекторы яктыларын күрәләр, дип эфирга хәбәр итүе моментыннан алып бу радиограмма Москвага алыну моментына кадәр берничә генә минут үтте. (ТАСС).



Красный путь заводының механика цехы строгале Альтав иптәш Галиакбәров. Ул, декабрь планын 268 процент итеп үтәде.

М. Солтанов фотосы.

Сталинчыл өченче бишьеллык исмендәге социалистик ярыш

ЯҢА ЙӨКЛӘМӘЛӘР АЛАЛАР

Серго Орджоникидзе исмендәге завод коллективы Москвадагы инструменталь завод коллективы мөраҗәгатенә стахановча эш белән җавап бирә. Бу уңай белән цех һәм бүлекләрнең эшчеләре, инженер-техник работниклары үз өсләренә яңа йөкләмәләр алдылар.

Кызыл байраклы цехның иптәш Михайлов җитәкчелегендәге мастерской коллективы социалистик ярыш договорларының үтәлешен тикшерде. Ярышта беренчелекне алган өчен мастерской коллективы цехның күчмә кызыл байрагы белән бүләкләнде.

Мастерскойның алдынгы стахановчысы—фрезеровщик иптәш Нотфуллин:

— Москваның инструменталь завод коллективы мөраҗәгатенә җавап итеп 1940 нчы елның программасын 200—250 процент итеп үтәргә сүз бирәм һәм мастерскойның барлык стахановчыларын социалистик ярышка чакырам, диде.

Мастерской коллективы цехның күчмә кызыл байрагын үзендә нык саклау өчен тагын да яхшырак эшләргә булды.

Начальнигы иптәш Закутаев булган цехның мастерское коллективы мөраҗәгаткә җавап итеп, гыйнвар ае программасын югары сыйфатлы итеп 200 процент үтәргә һәм уйлап табу такдиме бирергә йөкләмә алды.

Начальнигы иптәш Андриянов булган цех коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген 20 процентка күтәрергә, бракны 20 процент киметергә, күп профессияне үзләштерү эшен җәелдерергә, станокларга ремонт ясау эшен кыска срокта үтәргә йөкләмәләр алдылар.

Цех коллективы үз өстенә алган йөкләмәсен намус белән үти башлады. Катлаулы станокның техникасын үзләштереп, яхшы детальләр җитештерә башлады. Элек бер детальне эшләү өчен 4 сәгать вакыт үтсә, хәзер ул 15 минутта эшләнә һәм детальнең сыйфаты яхшы була. *Г. Ялышов.*

УҢЫШЛАРНЫ НЫГЫТАЛАР

Мехкомбинат предприятиеләре үткән елның производство заданиесен срогыннан элек үтәп, 1940 нчы елны уңышлы каршыладылар. Хәзер коллектив бу уңышларны ныгыту өчен көрәшә. 3 нче мех фабрикасы гыйнвар аеның беренче биш көне планын 119,1 процент, 2 нче номерлы мех фабрикасының скорняк-тегү цехы 159,1 процент, 1 нче мех фабрикасы 102 процент итеп үтәделәр.

1 нче мех фабрикасының буяу цехында хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүдә яңа уңышларга ирешелде. Цехта Сабирҗанова, Гыйсматуллина иптәшләрнең сменалары аеруча яхшы эшлиләр. Бу сменаларда бишькөнлек задание 132—176 процент итеп үтәлде. Стахановчы иптәш Данилова 5 нче гыйнвар көнне бер сменага 23 пар урнына 160 пар мех бияләй эшләп, норманы 695 процент итеп үтәде. Манто-яка цехы коллективы да бик яхшы эшли башлады. Бу цехның иптәш Хасанова бригадасы бишькөнлек заданиене 322,7 процент үтәде.

Мехкомбинат буенча бишькөнлек план үтәлеше 106,9 процент булды.

Язу машиналары эшләү заводының аерым участкылары һәм цехлары гыйнвар аеның беренче биш көнендә шактый яхшы эшләделәр. Заводның хәзерләү цехы коллективы бишькөнлек планны 114,4 процент итеп үтәде. Аерым стахановчылардан Гурьянов һәм Сердобольский иптәшләр норманы 288—405 процент итеп үтәделәр.

Механика цехының фрезер участкысы да яхшы эшли. Бу участкы буенча бишькөнлек задание 180,3, комсомолка иптәш Иванова участкысы шул ук вакытка заданиене 102,4 процент итеп үтәде.

БИШЬКӨНЛЕК ПЛАН АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

1 нче тегү фабрикасының беренче цех коллективы яңа елны хезмәт җитештерүчәнлеген шактый югары күтәрү белән каршылаган иде. Цех план үтәү буенча хәзер дә алда бара. 4 нче гыйнварда көнлек планны 110,3 һәм 5 нче числода 118 процент итеп үтәде.

Мастерлардан Габдуллаҗанова, Садыйкова, Александрова, Клеменкова иптәшләрнең сменалары гыйнвар аеның беренче 5 көнлек планын арттырып үтәделәр. Иптәш Клеменкова сменасында эшләүчеләрдән Җиһаншина, Исламова һәм Шишкина иптәшләр беренче гыйнвардан башлап икешәр операция башкаруга күчтеләр һәм алар хәзер көнлек нормаларын 130—180 процент итеп үтәүгә ирештеләр.

Аерым стахановчылардан Губаева, Ситдикова, Хәбибуллина һәм Федорова иптәшләр сменага бер ярым, хәтта икешәр норма бирәләр. Сабирова, Шәрифуллина һәм Алексеева иптәшләр эш тәҗрибәләрен уртаклашуда үрнәк күрсәтәләр. Алар, производствога яңа килгән яшь эшчеләрдән Волкова, Удучкина, Артемьева һәм Аксенова иптәшләрне стахановча эшләү методларына өйрәтәләр.

Рәхмәтуллина.

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫНЫҢ УТЛАРЫ ТОРГАН САЕН АЧЫГРАК КҮРЕНӘЛӘР

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧ БОРТЫ 7 гыйнвар. (ТАСС). Кичә, „Седов“ хәрәкәт итә торган районда көн болытлы иде. Вакыт-вакыт кар яуды. Температура — минус 23 градус. Көньяк-көнчыгыштан искән көчле җил пароходны төньяк-көнбатышка таба алып китте. Көн уртасында координатларны билгеләдек—төньяк киңлек 88 градус, 49,3 минут, көнчыгыш озынлык 2 градус 11 минут. Төнлә белән бозларның бер кадәр кысылуы сизелде. „И. Сталин“ бозваткычының утлары торган саен ачыграк күренәләр.

Пароходта барсы да тәртиптә, һәр кем шат һәм сәламәт.

Н. Бекасов.

БОЛГАРИЯ СӘҮДӘ ДЕЛЕГАЦИЯСЕНЕҢ МОСКВАДАН КИТҮЕ

Болгариянең финанс министре Божилов әфәнде җитәкчелегендәге һәм Гунев, Славянов, Добрев, Костов, Сарафов, Васильев әфәнделәр составындагы сәүдә делегациясе 7 нче гыйнварда Москвадан китте.

Киев вокзалында аларны чит ил эшләре наркомы урынбасары иптәш В. Г. Деканозов, тышкы сәүдә наркомы урынбасары иптәш В. И. Кушаров, финанс наркомы урынбасары иптәш В. Ф. Попов, Наркоминделның протоколлар бүлеге мөдире иптәш В. Н. Барков, Наркоминделның Якын Көнчыгыш бүлеге мөдире иптәш Н. В. Новиков, Наркомвнешторгның договорлар бүлеге начальнигы хезмәтләрен үтәүче иптәш Д. Д. Мишуссин, Нармвнешторгның протоколлар бүлеге мөдире иптәш С. А. Бшивков, Наркомвнешторгның Болгария буенча референты иптәш А. В. Биляев һәм Болгария миссиясе составы озаттылар.

ХРОНИКА

7 нче гыйнварда Болгариянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Н. Антонов әфәнде Москвадан китте.

Киев вокзалында Н. Антонов әфәндене Наркоминделның протоколлар бүлеге мөдире иптәш В. Н. Барков, Наркоминделның Якын Көнчыгыш бүлеге мөдире иптәш Н. В. Новиков, Болгариянең дипломатия корпусы һәм Болгария миссиясе составы озаттылар.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

7 нче гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады. **Ухта** һәм **Реболы** юнәлешләрендә разведчикларның эзләнүләре булды. **Петрозаводск** юнәлешендә безнең разведка отрядларыбызның берсе дошман отрядын тар-мар итте. **Карелия** бугазында разведчикларның эзләнүләре һәм артиллериядән атыш барды. Һава начар булганлыктан авиациянең хәрәкәтләре чикләнгән характерда булды.

ИПТӘШ ТЕРЕНТЬЕВНЫҢ САРАҖОГЛЫ ЯНЫНДА БУЛУЫ

ӘНКАРӘ, 7 гыйнвар. (ТАСС). СССР ның Төркиядәге илчесе иптәш Терентьев кичә Сараҗоглы янында булды һәм Көнчыгыш Анатолида җир тетрәүдән зыян күрүчеләргә ярдәмгә Совет Хөкүмәтенең 10 мең доллар акча җибәргәнлеге хәбәр итте. Сараҗоглы СССР хөкүмәтенә СССР ның бу дуслык актының кадрен белүче Төркия хөкүмәтенең һәм төрек халкының чын күңелдән рәхмәт белдерүен тапшыруын сорады.

ПАРТИЯ ПРОПАГАНДАСЫН ҮЗГӘРТЕП КОРУНЫҢ ЙОМГАКЛАРЫ

Пропаганда һәм агитация работникларының өлкә киңәшмәсендә ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеевның 1940 нчы ел, 4 нче гыйнварда ясаган докладыннан

Партиябез, Ленин—Сталин партиясе кадрларыбызны җәмгыят үсеше һәм политик көрәш законнарын белү белән, революциянең хәрәкәтләндерүче көчләрен белү белән коралландыручы марксизм-ленинизм теориясенә һәр вакыт гаят зур әһәмият биреп килде. Партиябез туган вакытта ук инде Владимир Ильич Ленин „революцион теориясез революцион хәрәкәт тә була алмый“ һәм „алдынгы көрәшче ролен тик алдынгы теория белән җитәкләнә торган партия генә үти ала“ дигән иде. Иптәш Сталин безне болай дип өйрәтә: революцион теория „... хәрәкәткә ул, һәм тик ул гына, ышаныч эш итүне, ориентировка көчен һәм әйләнә-тирәдәге вакыйгаларнең эчке багланышын аңлауны бирә ала, чөнки практикага ул, һәм тик ул гына, сыйныфларның хәзерге көндә ничек һәм кая таба хәрәкәт итүләрен генә түгел, бәлки аларның якын киләчәктә ничек һәм кая таба хәрәкәт итәргә тиешлекләрен дә аңларга ярдәм итә ала“.

ВКП(б) ның XVIII нче съездында иптәш Сталин болай диде:

„Ышаныч белән әйтергә мөмкин ки, әгәр дә без эшнең барлык тармакларындагы кадрларыбызны идеологик яктан хәзерләргә, эчке һәм халыкара обстановкага иркен төшенә алырлык дәрәҗәдә политик яктан чыныктырырга булдыра алсак иде, әгәр дә без аларны илгә җитәкчелек итү мәсьәләләрен җидди ялгышлардан башка хәл итәргә сәләтле булган, тәмам өлгереп җиткән марксистлар-ленинчеләр итә алсак иде,—ул вакыт безнең барлык мәсьәләләребезнең уннан тугызы инде хәл ителгән дип санарга барлык нигезләребез булыр иде. Ә бу бурычны без һич шиксез хәл итә алабыз, чөнки бездә аны хәл итү өчен кирәк булган барлык средстволар һәм мөмкинлекләр бар“.

Кадрларыбызның теоретик артталыгын бетерү өчен, аларны большевизм белән коралландыру өчен партия күп кенә гаять әһәмиятле чаралар үткәрде. ВКП(б) Үзәк Комитеты комиссиясе, иптәш Сталинның иң якыннан торып катнашуы белән, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н—марксизм-ленинизм өлкәсендәге төп белемнәрнең шушы энциклопедиясен эшләде. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу партиябезнең идея тормышында гаять зур вакыйга булды. Үзәк Комитет „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу уңае белән партия пропагандасының куелышы турында махсус карар кабул итте. Бу карарда партия пропагандасы куелышындагы төп кимчелекләр күрсәтелде, аларны бетерү юллары билгеләнде. ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан күрелгән бу гаят әһәмиятле чаралар партиянең бөтен идея-политик эшен күтәрү өчен куәтле этәргеч бирделәр һәм партия пропагандасы эшен тагын да югарырак яңа баскычка күтәрү өчен барлык кирәкле шартларны тудырдылар.

ВКП(б) Үзәк Комитеты үзенең 1938 нче ел 14 нче ноябрь карарында, партия пропагандасы куелышында төп кимчелек партия пропагандасы эшенә үзәкләштерелгән җитәкчелекнең булмавыннан һәм шушыннан килеп чыга торган кустарчылыктан һәм оешмаганлыктан гыйбарәт икәнлекне күрсәтте. Бу кустарчылык һәм оешмаганлык шуннан гыйбарәт иде ки, партия пропагандасының төп формасы итеп түгәрәкләр аркылы телдән пропаганда алып баруны сайлап алдылар, „пропаганда да түгәрәкләр методы партиянең легаль булмаган чорындагы эш шартлары аркасында күбесенчә шул заманга хас метод булганлыгын... оныттылар“.

Безнең шартларда марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүнең төп методы большевиклар партиясенең тарихын һәм теориясен үзлегеңнән өйрәнү методы булырга тиеш. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ һәм Үзәк Комитет карары чыкканнан бирле елдан артык вакыт үтте. Бу вакыт эчендә партиянең Татарстан оешмасы партия пропагандасын үзгәртеп кору буенча, ВКП(б) членнарын һәм кандидатларын политик тәрбияләү һәм теоретик чыныктыру буенча шактый зур эш эшләде. Татарстанның партияле һәм партиясез большевиклары, совет интеллигенциясе марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүгә зур дәрт белән керештеләр. Кадрларыбыз большевиклар партиясе тарихын, марксизм-ленинизм калассикларының әсәрләрен зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

Татарстан хезмәт ияләре арасында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның һәм Маркс, Энгельс, Ленин һәм Сталин әсәрләренең басылып таралуы турындагы саннар партияле һәм партиясез большевикларның революцион теорияне үзләштерүгә гаят дәрәҗәдә омтылуларын ачык күрсәтәләр. 1939 нчы елны республиканың китап сәүдәсе оешмалары 150 мең данә „Кыскача курс“ (шулардан 74 мең данәсе татар телендә һәм башка телләрдә), марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен 323 мең данә саттылар (шулардан 192 мең данәсе татар телендә һәм башка телләрдә). Ләкин теоретик мәсьәләләр буенча язылган әдәбиятка һаман үсеп бара торган сорауны шушы кадәр сандагы китаплар да канәгатьләндереп бетерә алмыйлар әле.

Предприятиеләрдә, колхозларда, учреждениеләрдә һәм вузларда меңнәрчә кешеләр революцион теорияне һәм большевизм тарихын үзлекләреннән өйрәнәләр. Теория белән кызыксынуның артуы, үз көчләренә һәм иң әһәмиятле фәнне—марксизм-ленинизмны үзләштерү сәләтенә ышанычның ныгуы үзлегеңнән укуның төп нәтиҗәсе булды. Берничә мисаль алыйк.

Партиянең Минзәлә район оешмасындагы ВКП(б) члены иптәш Майоров (педагогик училище укытучысы) үзенең идея-политик дәрәҗәсен системалы рәвештә күтәрә бара. Ул инде „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н тулысынча өйрәнеп бетергән. Шуның белән бергә иптәш Майоров Маркснын „Франциядә 1848 нче елгы революция“ дигән әсәрен, Маркс һәм Энгельснең „Коммунистик манифест“ын, Энгельснең „Табигать диалектикасы“н һәм „Людвиг Фейербах“ын, Лениннең „Нәрсә эшләргә?“, „Бер адым алга, ике адым артка“, „Ике тактика“ һәм башка әсәрләрен, Сталинның „Ленинизм мәсьәләләре“н һәм башка бик күп кенә әсәрләрен укып чыккан. Иптәш Майоров җәмәгать-политик тормышта актив катнаша. Партиянең башлангыч оешмасы секретаре буларак, ул „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүчеләр белән тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре һәм теоретик мәсьәләләр буенча беседалар үткәрә.

Партиянең Минзәлә оешмасында ВКП(б) ның башка членнары да үзләрен үстерү юлында бик тырышып һәм күңел биреп эшлиләр. Шулардан Әхмәтҗанов, Әхметов, Меркурьев, Тимофеев, Измайлов, Моратов һәм башка иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. Алар барсы да „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н тулысынча өйрәнгәннәр һәм тулы итеп төзелгән конспектлары бар. Партия тарихын өйрәнгәндә бу иптәшләр Ленин һәм Сталин әсәрләреннән киң файдаланганнар. Партия пропагандасы куелышының яхшыруы районда бөтен партия эшенең яхшыруында да күренә. Элек Минзәлә районы артта баручы район иде, ә хәзер ул үзенең артталыгын бетерә һәм республиканың алдынгы районнары сафларына чыгарга тырыша.

Мамадыш районының урта мәктәп директоры иптәш Гришин „Кыскача курс“ны өйрәнүне тулысынча тәмам иткән һәм конспект төзегән. Шуның өстенә ул Маркс һәм Лениннең күп кенә әсәрләрен укып чыккан һәм аларга да конспектлар төзегән. Иптәш Гришин—партия кабинетының иң яхшы консультантларыннан берсе. Тәмте районы прокуроры иптәш Кукарников, Тәмте райкомының хәрби бүлек мөдире иптәш Елагин, Тәтеш райкомының парткабинет мөдире иптәш Васин һәм башка иптәшләр дә белемнәрен арттыру өстендә тырышып эшлиләр.

Революцион теорияне өйрәнүгә партиясез иптәшләрнең дә җидди караулары турында күп кенә мисальләр китерергә мөмкин. Ширәмәттә районара колхоз мәктәбенең партиясез укытучысы иптәш Душкин революцион теорияне үзләштерүдә тырышып эшли. Иптәш Душкин менә болай ди:

— Мин үземнең эшемә нигез итеп „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н алдым. Хәзер инде 12 бүлекнең барсын да өйрәндем. Китап өстендә системалы рәвештә эшлим, моңа көн саен ике сәгать бирәм. Аерым мәсьәләләргә тирәнрәк төшенү өчен бер үк вакытта Маркс, Энгельс, Ленин һәм Сталин әсәрләрен өйрәнәм. Партия кабинеты миңа зур ярдәм күрсәтә. Анда миңа кыен мәсьәләләрне төшенергә ярдәм итәләр, тиешле әдәбият сайлап бирәләр һәм шунда ук мин ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторларының лекцияләрен тәртипле рәвештә тыңлыйм. Хәзер мин үземнең алдыма Маркснын „Капитал“ын тирәнтен өйрәнү бурычын куйдым.

Мондый мисальләрне күп китерергә мөмкин. Алар барсы да йөзләрчә һәм меңнәрчә партияле һәм партиясез большевикларның, совет интеллигенциясенең „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ нигезендә марксизм-ленинизм теориясен гаят зур теләк һәм кызыксыну белән өйрәнүләрен, үзләренең теоретик артталыкларын бетерүләрен күрсәтәләр.

Билгеле, партиянең җитәкче работниклары марксизм-ленинизмны үзләштерүдә үрнәк күрсәтергә тиешләр. Партия тарихын өйрәнү гаят әһәмиятле икәнлекне аңлаган иптәшләрдән ВКП(б) ның Киров райкомы секретаре иптәш Тихоновны, Калинин райкомы секретарьлары Вәлиуллин, Садертинов һәм Сәлимов иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. Алабуга райкомы секретаре Петров һәм Ворошилов райкомы секретаре Сәмигуллин иптәшләр дә белемнәрен арттыру өстендә яхшырак эшли башладылар. Башка кайбер райком секретарьлары да үзләренең белемнәрен арттыру эшен яхшырттылар. Ләкин, кызганычка каршы, партия пропагандасы турында ВКП(б) Үзәк Комитеты карарыннан үзләре өчен бер нинди дә нәтиҗәләр ясамаган, укуга күңел биреп карамаучы һәм үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрмәүче җитәкче работниклар да бар әле. Мәсәлән, „Строитель“ комбинаты директоры Игнатов, Татсоюз председателе Осинцев, ТАССР ның җир эшләре наркомы Черзор, житен комбинаты директоры Косолапов, Кызыл Йолдыз районының уполнаркомзагы Мөхәммәтшин һәм башка иптәшләр.

Мондый фактлар, барыннан да элек, ВКП(б) райкомнары һәм партиянең башлангыч оешмалары секретарьларының, пропаганда һәм агитация бүлекләре работникларының үзлегеңнән индивидуаль политик белем алу эшен үз агымына куйган булуларыннан, үзеңнең аңлылыгыңны күтәрү һәм марксизм-ленинизм нигезләрен үзләштерү турында ВКП(б) уставын коммунистларның ничек үтәүләрен тикшермәүләреннән, коммунистларга тиешле ярдәм күрсәтмәүләреннән килеп чыкканнар. Шуна күрә дә партиянең һәм советның җитәкче работниклары үзлекләреннән политик белем алулары эшендә алар алдына куелган таләпләрне күтәрү бигрәк тә кирәк.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнүче коммунистлар белән райком секретарьларының, партиянең башлангыч оешмалары секретарьларының индивидуаль беседаларын үткәрергә, тәҗрибәләр уртаклашу буенча киңәшмәләр җыярга, партия членнарының һәм кандидатларының үзлекләреннән политик белем алуларының ничек баруын партия җыелышларында тикшерергә кирәк. Үзләрен үстерү юлында эшләмәүчеләргә, марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнмәүчеләргә карата Үзәк Комитетның 1939 нчы ел 16 нчы август карарында күрсәтелгәнчә җәмәгатьчелек фикерен күтәрергә кирәк.

МАТБУГАТНЫҢ РОЛЕН ТАГЫНДА ЮГАРЫРАК КҮТӘРЕРГӘ

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел, 14 нче ноябрь карарында болай диелгән: „Марксизм-ленинизм пропагандасында хәл иткеч төп корал—матбугат: журналлар, газеталар, брошюралар булырга тиеш, ә телдән пропаганда алып бару булышчы, ярдәмче урын тотарга тиеш“.

Татарстанда 7 өлкә газетасы, „Татарстан Большевигы“ журналы, 145 район газетасы һәм күп тиражлы газеталар чыга. Алар йөз меңнәрчә укучыларга хезмәт күрсәтәләр һәм партия пропагандасы куелышында хәл иткеч роль уйнарга тиешләр. Үткән елны безнең өлкә газеталары ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә ярдәмгә күп кенә консультацияләр һәм теоретик мәкаләләр басып чыгардылар. „Красная Татария“ 97, „Кызыл Татарстан“ 85, „Херле Ялав“ 60, „Комсомолец Татарии“ 41 һәм „Яш Сталинчы“ 47 мәкалә һәм консультация басып чыгардылар. РВ—17 радио станциясе буенча татар һәм чуаш телләрендә 111 лекция һәм консультация тапшырылды. „Татарстан Большевигы“ журналында теоретик темаларга 18 мәкалә урнаштырылды.

Өлкә газеталары үзләренең битләрендә партия кабинетларының, лекторларның, пропагандистларның эшләрен, үзлегеңнән укудагы яхшы тәҗрибәләрне күрсәтә торган күп кенә мәкаләләр һәм заметкалар да бирделәр. Мәсәлән, „Красная Татария“ врачларның белемнәрен арттыру буенча Казан институтындагы укытучылар составының теоретик дәрәҗәсен күтәрү буенча эш тәҗрибәсен киң күләмдә яктыртты. Газета битләрендә партиясез профессорлар — Козлов, Лепский һәм башка иптәшләр марксизм-ленинизм теориясен үзләренең ничек итеп үзләштерүләре һәм үзләренең фәнни һәм педагогик эшләренә моның нинди йогынты ясавы турында яздылар. „Красная Татария“ Чистай һәм Лаеш районнарында пропаганда эшенең куелышын шактый киң яктыртты. „Кызыл Татарстан“ һәм башка өлкә газеталары да пропаганда турында күп кенә эчтәлекле материаллар бирделәр.

Шуның белән бергә, газета битләрендә партия пропагандасы мәсьәләләрен куюдагы һәм яктыртудагы зур гына кимчелекләрне дә әйтеп үтәргә кирәк. Өлкә матбугаты әле марксизм-ленинизм фәнен үзләштерергә омтылучы партияле һәм партиясез большевикларның үсеп бара торган сорауларын канәгатьләндереп бетерми. Безнең газеталарыбыз әле ВКП(б) Үзәк Комитеты таләп иткәнчә марксизм-ленинизм пропагандасының чын трибунасы булып әверелмәгәннәр. Урыннардагы пропагандистлар һәм лекторлар газеталарда катнашуга җитәрлек тартылмыйлар. „Красная Татария“ да басылып чыккан 97 теоретик мәкаләдән һәм консультациядән бары 29 ы гына урындагы авторлар тарафыннан язылган. Иң яхшы пропагандистларның лекцияләрен өлкә газеталары бөтенләй диярлек басмыйлар. Өлкә газеталары тирәсендә әле иң яхшы укытучылардан, лекторлардан һәм пропагандистлардан даими актив юк.

Аннан соң өлкә газеталарында басыла торган теоретик мәкаләләрнең һәм консультацияләрнең партиябез тарихының күбесенчә Октябрьгә кадәрге чорына гына бәйләнгән булуы да аларның эшендә зур кимчелек. Бу нәрсә газеталарның беренче бүлекләрдән уза алмаучы һәм шуннан ары китмәүче, артта калучы иптәшләргә тигезләнүләрен күрсәтә. Матбугат пропаганданың файдалы тәҗрибәләрен йомшак туплый һәм йомшак популярлаштыра, пропаганда эшеннән читләшкән җитәкчеләрне һич тә җитәрлек тәнкыйтьләми.

Пропаганда мәсьәләләрен яктыртуда өлкә матбугатының өстән генә эш итүен, аның эчтәлегенә кермәвен, коры статистика белән генә мавыгуын әйтергә кирәк. Мәсәлән, „Кызыл Татарстан“ „Норлат районында пропаганда - агитация эшенең кайбер йомгаклары“ дигән материал урнаштырды. Бу мәкалә башыннан ахрына кадәр саннар белән тутырылган: ничә кеше тарихны өйрәнә, ничә консультация үткәрелгән, лекцияләрдә ничә кеше булган һ. б. ВКП(б) ның Саба райкомы пропагандисты иптәш Гарипов мәкаләсе дә шул ук стильдә язылган.

ВКП(б) Үзәк Комитеты үзенең карарында, пропаганда өлкәсендә сан артыннан куу партия оешмаларының төп буынны—пропаганданың сыйфатын кулдан ычкындыруларына китергәнлекне күрсәткән иде. Үзәк Комитет партия оешмаларына партия пропагандасын оештыруны аның сыйфатын, аның идея дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итәрлек итеп үзгәртеп корырга кушкан иде. Большевистик матбугат работниклары моны һәр вакыт исләрендә тотарга тиешләр. Матбугат пропагандасы өлкәсендә нинди бурычлар тора соң?

1. Өлкә матбугатында марксизм-ленинизм пропагандасын яхшырту өчен иң яхшы лекторларны, марксизм - ленинизм нигезләрен укытучыларны һәм югары квалификацияле башка пропагандист кадрларны редакцияләр тирәсенә берләштерергә кирәк.

2. Пропаганданың оештыру тәҗрибәсен киң күләмдә яктырту белән бергә, өлкә һәм район матбугаты аның идея эчтәлегенә тирәнтен төшенергә тиеш.

3. Марксизм-ленинизм теориясен үзләштерүчеләргә ярдәмгә мәкаләләр һәм консультацияләр басып чыгару эшенә өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге тарафыннан көндәлек җитәкчелекне тәэмин итәргә һәм контрольне көчәйтергә кирәк.

ЛЕКЦИЯ ЭШЕ

ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладында иптәш Сталин: „Пропагандада түгәрәкләр системасы белән мавыгуны дөрес түгел дип табып һәм марксизм-ленинизм нигезләрен партия членнарының индивидуаль өйрәнүләре методын максатка яраклырак дип санап, партиянең игтибарын матбугат аркылы пропагандага һәм пропаганданың лекцияләр системасын оештыруга юнәлдерү“ бурычын куйды.

Яхшы хәзерләнгән һәм эчтәлекле лекция—революцион теорияне һәм большевизм тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә зур ярдәм. Үткән елны республикабызда лекция эше киң колач алды. Барлык районнарда йөзләрчә лекцияләр укылды. Партиябез тарихы буенча лекцияләр тыңлау өчен иптәшләр уннарча километрлардан килделәр. Түбәндәге саннар лекция эшенең колачын күрсәтәләр. Барлыгы 3.092 лекция укылган, аларны 340.000 кеше тыңлаган. Шул исәптән ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторлары 632 лекция укыганнар, шулардан ВКП(б) тарихы буенча 305, философия буенча 200 һәм халыкара хәл буенча 94 лекция.

Болар барсы да кадрларыбызның марксизм-ленинизм теориясен өйрәнү белән кызыксынулары үскәнлекне күрсәтәләр. Мәсәлән, Беренче Май районының Кадеевка авылында шундагы интеллигенция өчен оештырылган лекциядә 35 кеше булды. ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторы иптәш Емельяновка 15 сорау бирелде. Менә аларның кайберләре: „Нәрсә ул абсолют хәкыйкат?“, „Нәрсә ул диалектика һәм эволюция?“, „Фейербахның төп әсәрләре ниндиләр?“, „Нәрсә ул нәселдән күчү һәм үзгәрүчәнлек?“ һ. б. Бу сораулар үзе генә дә бик күп нәрсәләрне аңлата. Ул, безнең кадрларыбызның бик нык тырышып укуларын, югары белемле кешеләр булып баруларын күрсәтә.

Мондый аудитория алдында лекцияләр белән чыгу җиңел эш түгел, моның өчен зур теоретик хәзерлек кирәк. Бу безнең лекторларыбызны күп эшләргә, үзләренең квалификацияләрен күтәрергә мәҗбүр итә. Соңгы елларда Татарстанда яхшы гына лекторлар кадрлары үсте. Алар революцион теорияне өйрәнүчеләр арасында популярлек һәм авторитет казандылар. Шундыйлардан ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты лекторы иптәш Тимофеевны, партиянең Өлкә Комитетының даими лекторларыннан Семкин, Гайнетдинов һәм Бохараев иптәшләрне, штаттан тыш лекторлардан Морозов, Мелещенко һ. б. иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. ВКП(б) ның Чистай райкомының да квалификацияле лекторлары бар. Болар беренче чиратта Саксин һәм Пермякова иптәшләр. Бу иптәшләрнең лекцияләрен бик яратып тыңлыйлар. ВКП(б) ның Чистай райкомы ВКП(б) тарихы буенча, диалектик һәм тарихи материализм буенча, халыкара хәл буенча үз көчләре белән 105 лекция үткәрде. Боларда 15 меңгә якын кеше булды.

Өлкә Комитеты һәм Шәһәр Комитеты лекторлары укыган лекцияләр идея ягыннан җитәрлек кадәр югары дәрәҗәдә үттеләр. Күп кенә лекцияләр башта Өлкә Комитетының һәм Шәһәр Комитетының пропаганда һәм агитация бүлекләрендә каралдылар. Ләкин әйтергә кирәк, Өлкә Комитеты да, Шәһәр Комитеты да партиянең район оешмаларындагы лекторларның эшләренә контрольне тиешенчә оештырмаганнар әле. Лекцияләр стенографиягә язып алынмаганнар, лекцияләрнең тезислары лекторлар группаларында һәр вакытта да тикшерелмәгән. Шунлыктан кайбер уңышсыз лекцияләр булу фактлары очраклы хәл түгел. Мәсәлән, Бөгелмәдә иптәш Сафронов шундый хәлгә очрады. Ул „Тарихта шәхеснең роле“ дигән бер тема эчендә философиянең бөтен тарихын күрсәтеп бирергә теләгән. Өлкә Комитетның пропаганда һәм агитация бүлеге партия райкомнары лекторларының эшенә аз игтибар бирә. Бу яктан Чистайда иптәш Пермякова лекцияләренең тезислары бик характерлы. Бу лекцияләр Өлкә Комитетына рецензиягә җибәрелгәннәр иде. Тезисларны бер кем дә укымаган һәм аларга рецензия бирелмәгән.

Тагын бер зур кимчелек турында. Укылган лекцияләрнең күпчелеге үзләренең тематикалары буенча партия тарихының Октябрьгә кадәрге чорына кагылалар. Күп кенә районнарда, мәсәлән, Буа районында Октябрьдән соңгы чор турындагы темага әле бер лекция дә укылмаган. Бу безнең эшебездә бик зур кимчелек. Мондый практика кадрларыбызның партия тарихын өйрәнүләренә тоткарлык ясый.

Оештыру хәзерлегенең лекцияләрне уңышлы үткәрү өчен гаят зур әһәмияте бар. Соңгы вакытларда Өлкә Комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге булачак лекцияләр турында райкомнарга алдан хәбәр итә башлады. Бу, тыңлаучыларны яхшырак хәзерләргә мөмкинлек бирә. Ләкин һаман да әле лекцияләрнең оешмаган төстә үтүләре сирәк түгел. Норлат, Яңа Писмән, Молотов, Яңа Чишмә һәм башка райкомнарның лекция сәгатьләрендә бюро утырышы билгеләүләре яки берәр киңәшмә җыюлары кебек хәлләр булды. Буденный, Югары Ослан, Чүпрәле һәм башка күп кенә районнарда аерым лекцияләрне өзү фактлары булды. Һич шиксез, бу хәл, партиянең бу райкомнары җитәкчеләренең лекция эшенә җитәкчелек итүдән читкә китүләреннән, аны үз агымына куюларыннан килеп чыккан.

Лекция эше куелышының тәҗрибәсе түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мәҗбүр итә:

1. Лекцияләрне оештыру ягыннан хәзерләүгә иң җидди игтибар бирергә кирәк. Лекцияләрнең тематикасы турында коммунистларга һәм тыңлаучыларга алдан хәбәр итәргә кирәк.

Шулай ук лекцияләрнең темалары буенча марксизм-ленинизм классикларының әсәрләреннән, шулай ук ярдәмче материаллардан тиешле күргәзмәләр оештыру да бик яхшы булачак.

Лекцияләрнең нормаль үтүе өчен барлык шартларны тудырырга кирәк (язып барырга мөмкинлек бирү, карталар, иллюстратив материаллар хәзерләү һ. б).

2. Киләчәктә лекцияләрнең тематикасы „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның барлык 12 бүлеген дә эченә алырга тиеш. Ләкин төп игтибарны Октябрьдән соңгы чорга бирергә кирәк. Аерым кадрларның хәзерлек дәрәҗәсенә карап (түбәнге, урта һәм югаргы буын программасы буенча) аерым лекцияләр оештырырга кирәк.

3. Лекция эшенә ВКП(б) Өлкә Комитетының, Шәһәр Комитетының һәм партия райкомнарының пропаганда һәм агитация бүлекләре тарафыннан җитәкчелекне яхшыртырга һәм лекторларның үсүе өчен барлык кирәкле шартларны тудырырга кирәк.

ВКП(б) ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

Марксизм-ленинизмны өйрәнүнең төп методы—китап өстендә үзлегеңнән эшләү. Шуның белән бергә ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел 14 нче ноябрь карарында күрсәтелгәнчә, партия тарихын түгәрәкләрдә өйрәнергә теләүчеләр булганда һәм квалификацияле пропагандистлар булганда кадрларның түбәнге, урта һәм югаргы буыннары өчен аерым түгәрәкләр төзергә мөмкин. Шулай ук түгәрәкләрне ничек оештырырга кирәклеге һәм аларның ничек эшләргә тиешлекләре турында да карарда конкрет төстә күрсәтелгән.

Үзәк Комитет күрсәтмәләрен үтәп, партиянең Татарстан оешмасы түгәрәкләр санын шактый киметте. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыкканга кадәр партия тарихын өйрәнү буенча бездә 1.794 түгәрәк булса, 1939 нчы елның 1 нче декабренә аларның саны 350 гә кадәр кимеде. Ләкин эш санның кимүендә генә түгел, иң әһәмиятлесе шунда ки, түгәрәкләрнең эш методлары тамырдан үзгәрде.

Мәсәлән, Ютазы районы, „Авангард“ колхозы партия оешмасы янындагы түбәнге звено түгәрәге. Аңа пропагандист иптәш Ганиев җитәкчелек итә. Түгәрәктә 12 кеше бар. Алар барсы да занятиеләргә яхшы хәзерләнәләр, конспектлар төзиләр. Бу конспектларны пропагандист һәр вакыт тикшерә. Занятиеләргә йөреш 100 процент. Хәзер түгәрәк партия тарихының икенче этапын өйрәнә башлады. Занятиеләр тыңлаучыларның бик актив катнашулары белән җанлы һәм кызыклы үтәләр. Мондый уңышлы мисальләр башка районнарда да бар.

Шуның белән бергә, партия оешмаларының күпчелегендә түгәрәкләрнең эшендә бик зур җитешсезлекләр булуын әйтергә кирәк. Байтак кына районнарда түгәрәкләргә кешеләр туплау принципы бозылган. Партиянең Красный Бор райкомы пропагандисты иптәш Бикмуллина, кешеләрнең гомуми һәм политик белем дәрәҗәләренә карамастан, кем туры килсә, шуны түгәрәккә язган. Кузнечиха районында, Яңа Рәҗәп авылы партия оешмасы янындагы түбәнге буын түгәрәгендә укытучы Зиннәтев һәм укый-яза белми торган Шаһвәлиев иптәшләр торалар. Олы Тархан районында авыл интеллигенциясенең 30 лап вәкилләрен

(Ахры 3 нче биттә).

Партия пропагандасын үзгәртеп коруның йомгаклары

(Башы 2 нче биттә).

түбәнге буын түгәрәкләренә керткәннәр. Шул ук районда түгәрәкләрне тулы иреклелек нигезендә төзү принципы бозылган. Мәсәлән, Кильганов, Авдеева, Васин һәм башка иптәшләрне түгәрәкләргә үзләреннән башка язганнар.

Күп кенә түгәрәкләр тәртипле рәвештә эшләмиләр. Занятиеләр еш кына өзеләләр. Мондый фактлар Беренче Май, Алексеевск, Югары Ослан районнарында булган. Столбище районында түгәрәкләр гомумән эштән туктаганнар. Тыңлаучылар чираттагы занятиеләргә начар хәзерләнәләр, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н укымыйлар, конспектлар төземиләр. Бу эштә гаепнең шактый өлеше пропагандистлар өстенә төшә. Алар түгәрәкләр эшенең иң әһәмиятле бурычларыннан берсенә—тыңлаучыларның хәзерләнүләренә әһәмият бирмиләр, коммунистларны китап өстендә үзлекләреннән эшләргә өйрәтмиләр. Пропагандистлар кай вакытларда тыңлаучылар төзегән конспектларны да укымыйлар. Нәтиҗәдә конспектларда еш кына тупас политик ялгышлар була.

Күп кенә түгәрәкләрдә занятиеләрнең идея дәрәҗәсе түбән булуны күрсәтеп үтәргә кирәк. Партиянең Кузнечиха райкомының штаттагы пропагандисты иптәш Гордеев түбәнге буын түгәрәге занятиеләрендә, Плехановның народникларга каршы көрәше турында, Россиядә марксизмны җәелдерү буенча аның зур эше турында сөйләгәндә, шул чорда ук инде Плехановта меньшевистик карашлар туганлыгы турында бер нәрсә дә әйтмәгән. Мондый бер яклы гына характеристика, билгеле, тыңлаучыларны аптырашта калдырган һәм аларның берсе „ни өчен соң Плеханов соңыннан меньшевик булып әверелгән?“ дигән сорау биргән. Ә пропагандист „Аның ни өчен меньшевик булып әверелгәнен кем белсен!“ дип җавап биргән. Шул ук занятиедә иптәш Гордеев Ленинның „Нәрсә эшләргә?“, „Бер адым алга, ике адым артка“ һәм „Ике тактика“ кебек әсәрләрнең большевиклар партиясен оештыру өчен көрәштәге гаять зур роле турында бер нәрсә дә әйтмәгән генә түгел, хәтта Владимир Ильичның бу хезмәтләренә бөтенләй кагылмый да үткән.

Партия Өлкә Комитеты күптән түгел генә Кузнечиха һәм Олы Тархан районнарында түбәнге буын түгәрәкләренең эше турында карар кабул итте. Бу районнарда ачылган җитешсезлекләр Татарстанның байтак кына партия оешмаларында да бар. Шунлыктан Өлкә Комитеты ВКП(б) ның барлык райкомнарын түбәнге буын түгәрәкләрендә эшнең торышы мәсьәләсен тикшерергә һәм аларның эш сыйфатын күтәрү өчен кирәкле чараларны күрергә мәҗбүр итте.

Өлкә Комитет түбәндәгеләрне такдим итте: түгәрәкләрдә тыңлаучыларның составы гомуми белем һәм политик хәзерлек ягыннан бер төрле булуны тәэмин итәргә, түгәрәкләрнең эшен тәртипкә салырга, барлык тыңлаучыларның занятиеләргә калмыйча йөрүләренә, үзлекләреннән хәзерләнүләренә ирешергә, коммунистлардан үзләренең идея дәрәҗәләрен системалы рәвештә күтәрү турында ВКП(б) Уставын үтәүләрен таләп итәргә; түгәрәкләрнең эшендә Үзәк Комитет тарафыннан гаепләнгән мәктәпчелек, казенныйлык һәм схематизм методларына юл куймаска, занятиеләрне җанлы беседа һәм иптәшләрчә дискуссия нигезендә үткәрергә; түбәнге буын түгәрәкләрендә ВКП(б) тарихын кыскартылган күләмдә һәм теория мәсьәләләрен җиңелрәк аңларлык итеп, этаплар буенча өйрәнергә, занятиеләрнең озакка сузылуына юл куймаска; түгәрәкләргә көндәлек җитәкчелек итәргә, пропагандистларга һәм тыңлаучыларга системалы булышлык итәргә, занятиеләрнең планнарын тикшерү һәм тәҗрибә уртаклашу өчен пропагандистларны әледән-әле чакыруны кулланырга, тыңлаучылар өчен индивидуаль консультацияләрне системалы рәвештә үткәрергә.

ТЕОРЕТИК ТЕМАЛАРГА ИПТӘШЛӘРЧӘ БЕСЕДАЛАР ҺӘМ ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ БУЕНЧА КИҢӘШМӘЛӘР

Соңгы вакытларда, бигрәк тә ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел 16 нчы август карарыннан соң республикабызның күп кенә партоешмалары, теоретик темаларга иптәшләрчә беседалар һәм китап өстендә үзлегеннән эшләү тәҗрибәсен уртаклашу буенча киңәшмәләр кебек, пропаганда эшенең яңа формаларын куллана башладылар.

Казан шәһәр оешмасында, Бөгелмә, Югары Ослан, Минзәлә, Яңа Чишмә, Тәтеш һәм башка күп кенә район оешмаларында теоретик беседалар үткәрү аеруча киң рәвештә җәелдерелгәннәр.

Пропаганда работникларының инициатива күрсәтүләре, революцион теорияне үзләштерүче иптәшләргә булышлык итүнең төрле формаларын куллануларын яхшы эш. Билгеле, бу эштә, бигрәк тә теоретик беседаларны оештыру эшендә кайбер ялгышлар да була. Мәсәлән, Казанның Ленин районында теоретик беседалар кай вакыт урта буын түгәрәге занятиесенә әйләнә. Югары Ослан районының партия оешмаларында кайбер теоритик беседаларны эш тәҗрибәсе белән уртаклашу киңәшмәләреннән аеру кыен.

Ләкин аерым ялгышлар пропаганда эшенең бу яңа формаларының әһәмиятен һич тә кечерәйтмиләр. Безнең бурыч — теоретик беседаларны һәм тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләрен оештыруда һәм үткәрүдә иптәшләргә булышлык итү. Теоретик беседалар һәм тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре барлык партия оешмаларының эш практикасына керергә тиеш.

ПАРТИЯ КАБИНЕТЛАРЫ

Партия пропагандасының гомуми системасында партия кабинетлары зур роль уйныйлар. Алар үзләренең бөтен эшләре белән партияле һәм партиясез большевикларга марксизм-ленинизм нигезләрен үзлекләреннән өйрәнүдә булышлык итәргә тиешләр. Кайбер парткабинетлар җидди уңышларга ирештеләр. Индивидуаль һәм групповой консультацияләр, лекцияләр, семинарлар үткәрү—аларның эш системасына нык керделәр. Чама белән алынган саннарга караганда, 1939 нчы елны партия кабинетлары 2.500 групповой консультация үткәргәннәр. Чистай, Минзәлә, Мамадыш, Бондюг районнарында, шулай ук Казан шәһәрендә—пропаганда һәм агитация бүлекләре групповой консультацияләрне оештыру эшенә дөрес якын килгән урыннарда алар ВКП(б) тарихын өйрәнүче иптәшләргә ярдәмнең лекциядән кала төп формасы булып әверелделәр.

Партиянең Киров райкомының парткабинетында консультация эшенең кыйммәтле тәҗрибәсе бар. Кабинет тирәсенә штаттан тыш пропагандистларның ныклы активы тупланган. Алар күбесенчә югары белемле кешеләр—укытучылар, инженерлар. Алар барсы да райком бюросында расланганнар. Консультантлар арасында инженер иптәш Дэльвин башкалардан аерылып тора. Партия тарихын өйрәнүчеләр арасында ул урынлы буларак авторитетлы һәм танылган кеше. Апрельдән башлап, партия кабинеты 32 групповой консультация үткәрде, аларда 580 кеше катнашты.

Тикшерү—партия кабинетларының консультация эшенең теоретик дәрәҗәсе шактый югары икәнлекне күрсәтә. Ләкин партия райкомнары пропагандага җидди әһәмият бирмәгән урыннарда марксизм-ленинизмның аерым мәсьәләләрен аңлатуда җидди бозулар бар. Мәсәлән, Биләр райкомы пропагандисты иптәш Исмагыйлов Ленин исемендәге колхозда консультация вактында, программа минимум һәм программа максимум нәрсә ул?—дигән сорауга ялгыш җавап биргән. Партиянең Тәкәнеш райкомы пропагандисты иптәш Дьячкова, Әбде авылында консультацияләр үткәргән вакытта, РСДРП ның икенче съездындагы раскол турындагы мәсьәләне дөрес яктыртмаган.

Балтач, Дөбъяз, Кызыл Йолдыз, Чепья һәм башка кайбер районнарда групповой, шулай ук индивидуаль консультацияләрнең регуләр үткәрелмәү фактын партия кабинетларының йомшак эшләүләре белән генә аңлатырга мөмкин. Аларда бөтен ел буена групповой консультацияләр 9—10 тапкыр гына үткәрелгән. Бу хәлне һичбер нормаль дип әйтергә мөмкин түгел.

Кайбер пропаганда работниклары, партия кабинетларына коммунистларның начар йөрүләреннән, консультацияләрдән файдаланмауларыннан зарланалар. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел, 16 нчы август карарын бу иптәшләрнең исләренә төшерергә кирәк. Бу карар ярдәм сорап килүне пассив рәвештә көтеп ятучы партия кабинеты җитәкчеләрен кискен рәвештә гаепли. Партия кабинетлары партиянең башлангыч оешмалары белән, революцион теорияне өйрәнүче коммунистлар һәм интеллигенция белән нык бәйләнгән булырга тиешләр.

ПРОПАГАНДА РАБОТНИКЛАРЫ КАДРЛАРЫ

Соңгы вакытта йөзләрчә яңа кешеләр пропаганда эшенә күтәрелделәр. Алар көндәлек җитәкчелек һәм җидди ярдәм таләп итәләр. Алар белән һәр вакыт эшләргә, аларның тагын да үсүләренә ярдәм итәргә кирәк.

Бездә пропаганда работниклары составы түбәндәгечә: авыл райкомнарының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдирләре арасында белем ягыннан югары белемлеләр—5, урта белемлеләр 19, түбән белемлеләр 44 кеше; партия кабинетлары мөдирләре арасында югары белемлеләр—5, урта белемлеләр 19, түбән белемлеләр 41 кеше; пропагандистлар арасында югары белемлеләр—5, урта белемлеләр 54, түбән белемлеләр 106 кеше.

Бу саннар нәрсәне күрсәтәләр? Алар безнең пропагандистлар кадрларының барсына да җидди укырга һәм укырга кирәклекне күрсәтәләр. Пропаганда — ул ВКП(б) члены өчен мактаулы эш икәнлекне һәрбер пропагандист исендә тотарга тиеш. Партия мәгарифенә җитәкчелек эшен партия политик тотнаклы, иң нык сыналган, хәзерлекле коммунистларга гына ышанып тапшыра. Большевизм идеяләрен җәелдерүче, партиялеләр массасын тәрбияләүче булу—ул гаять мактаулы эш, ул—зур ышаныч. Алар белән горурланырга, аларның кадрен белергә һәм аларны көндәлек большевистик эш белән акларга кирәк.

* * *

Шулай итеп, партиянең Татарстан оешмасы үткән ел эчендә партия пропагандасын ВКП(б) Үзәк Комитеты күрсәтмәләре нигезендә үзгәртеп кору өлкәсендә шактый зур уңышларга иреште. Пропагандистлар кадрлары үсте, матбугат эшенең дәрәҗәсе күтәрелде, үзлегеннән уку белән кызыксыну артты. Шул ук вакытта партия пропагандасы эшенең куелышында байтак җидди җитешсезлекләр барлыгын да әйтергә кирәк. Күп кенә җитәкче работникларның, бигрәк тә партия һәм совет җитәкчеләренең үзлекләреннән укулары йомшак булу әле һаман да иң җидди кимчелекләрнең берсе булып кала.

Югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү бик мөмкин. Партия пропагандасы эшенә, ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел, 14 нче ноябрь карарын тормышка ашыру эшенә, ВКП(б) Өлкә Комитетының тиешле күрсәтмәләрен үтәүгә тагын да җиддиерәк тотынырга гына кирәк.

ВКП(б) ның XVIII нче съездының тарихи карарларын, ВКП(б) Үзәк Комитеты карарларын һәм бөек Сталинның **(көчле кул чабулар)** даһи күрсәтмәләрен үтәү нигезендә пропаганда эшенең тагын да ныграк үсәчәгенә һәм чәчәк атачагына шик юк. **(Кул чабулар).**

Казан тимер юлының 6 нчы дистанциясе өчен хатын-кызлардан юл обходчиклары хәзерләп чыгару курсында дәрес вакты. И. Галиев фотосы.

Кадрлар хәзерләүгә гамсез караш бетерелсен

Авыл хуҗалыгының алдынгы техника белән елдан-ел ныграк коралландырыла баруы, агротехниканың колхоз кырларында көннән-көн киңрәк урын ала баруы үз эшенең техникасын яхшы үзләштергән, теоретик хәзерлекле кадрларга гаять зур таләп куя.

Димәк, барлык районнардагы җир органнары, партия, совет оешмалары җитәкчеләре кадрлар хәзерләүне үзәк бурычларның берсе итеп куярга, аңа большевистик җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр. Кызганычка каршы, кайбер районнарның җир бүлекләре работниклары моны аңларга теләмиләр. Мисаль өчен Юдино районын алырга кирәк. Бу районнан хисапчылыкка уку өчен Әтнәдәге районара колхоз мәктәбенә 17 кеше, кырчылык бригадирлыгына уку өчен 16 кеше һәм яшелчәчелек бригадирлыгына уку өчен 6 кеше җибәрелергә тиеш. Алар үткән елның 1 нче октябрендә ук Әтнәгә килергә тиешләр иде. Укулар башланганга 3 айдан артык вакыт үтүгә карамастан, Юдино районыннан бер генә кешенең дә килгәне юк.

Курсантларның килмәве турында Юдино районы җир бүлеге мөдире иптәш Козловка өч тапкыр хат, ике тапкыр телеграмма җибәрелде. Аның өстенә шушы мәсьәлә буенча бу районга мәктәптән ике тапкыр махсус кеше җибәрелде. Ләкин бу чаралар һичбер нәтиҗәсез калдылар. Иптәш Козлов кадрлар хәзерләү буенча үзендә һичбер җаваплылык сизми. Ул: „курсантларның укырга бармавына мин гаепле түгел, мин берәүгә дә курска бармагыз дип әйткәнем юк“, дип кул гына селти. Бу, Козловның шушындый әһәмиятле эшкә бюрократларча каравын күрсәтә торган факт.

Юдино районыннан курска берәүнең дә җибәрелмәве турында һәм тиешле кешеләрнең килүен тәэмин итүне сорап ВКП(б) райкомына һәм район советына да берничә тапкыр мөраҗәгат ителсә дә нәтиҗәсез калды. Алар бу эшне район җир бүлегенә тапшырып, бөтенләй тынычланып калганнар.

Кадрлар хәзерләү мәсьәләсенә район җитәкчеләре шулай гамсез карагач, райондагы кайбер колхоз председательләренең бу эш белән бөтенләй шөгыльләнмәүләренә гаҗәпләнергә дә урын калмый.

Арча районында да курска укучылар туплау канәгатьләнерлек түгел. Бу районнан кырчылык бригадирлары курсына 14 кеше урынына бары ике генә кеше килде. Район җир бүлеге мөдире иптәш Нәҗметтинев бу эшне техник работникларга тапшырган.

Хатын-кызлардан кадрлар хәзерләү планы үтәлми. Мәктәптә укучы 73 кешенең 15 е генә хатын-кызлар. Әтнә районының Олы Бәрәзә авылы, Куйбышев исемендәге колхоз председателе Җиһаншин хатын-кызларны курска җибәрүгә теше-тырнагы белән каршы тора. Шул районның Мендеш авылы колхоз председателе Хәйруллин да шундый ук юлга баскан.

Әтнәдәге районара колхоз мәктәбе быелгы уку елында колхозлар өчен 85 хисапчы, 115 бригадир һәм 30 яшелчәчелек бригадиры хәзерләргә тиеш. Бу гаять зур һәм җаваплы бурыч. Аны уңышлы башкару өчен мәктәп коллективының яхшы эшләве белән бер рәттән, аңа беркетелгән районнарның (Әтнә, Арча, Кызыл Юл, Дөбъяз, Чепия, Юдино районнары) җитәкчеләреннән җидди булышлык таләп ителә.

Ш. Галимҗанов.

Өченче бишьеллыкта Татарстан халык хуҗалыгы

В. Быстров.
Татарстан АССР Госпланы председателе.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды өченче бишьеллыкта СССР халык хуҗалыгы үсешенең гаять зур программасын кабул итте.

„Өченче бишьеллык план—без кергән яңа чорга ярашлы план. СССР инде үсешнең яңа полосасына, сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзүне тәгәлләү һәм тәземле рәвештә социализмнан коммунизмга күчү полосасына керде,—бу план шуңа ярашлы“ (Молотов).

Партиянең XVIII нче съезды үзенең карарында төп экономик бурычны **„Европаның иң алга киткән капиталистик илләрен һәм Америка Кушма Штатларын экономик яктан да куып җитү һәм узып китү“** бурычын һәм бу бурычны якындагы чорда хәл итүне бөтен тулылыгы белән куйды. СССР халык хуҗалыгы үсешенең өченче бишьеллык планы—сугышчан эш программасы.

Өченче бишьеллыкта партияле һәм партиясез барлык большевикларның бурычы— илнең җитештерү көчләрен барлык чаралар белән үстерү.

Совет халкының бөек семьясендә орденлы Татарстан Сталинчыл бишьеллыклар чорында социализм өчен көрәштә алдынгы сафларда торды һәм тора. Дәүләт промышленносты продукциясе, 1932 нче ел белән чагыштырганда, 1937 нче елны ике тапкыр, кооператив промышленность продукциясе ике тапкырдан да артыграк (214,4 процент) үсте. Эре промышленностьның барлык продукциясенең гомуми күләме 1937 нче елда 740 миллион сумга җитте. 1937 нче елда авыл хуҗалыгының җәмагатьләштерелгән секторы барлык чәчү мәйданының 99,5 процентын эшләде. 1937 нче елда авыл хуҗалыгы продукциясе, 1932 нче елга караганда, 1,8 тапкыр үсте.

Сталинчыл бишьеллыклар чорында Татарстанда промышленностьның бөтенләй яңа тармаклары: машина төзелеше, химия (ясалма каучук), кинопленка промышленносты һәм башкалар төзелде. Шактый зур күләмдә төзү материаллары промышленносты тудырылды, агач эшкәртү заводлары, мех фабрикалары һ. б. салынды.

Суднолар төзелеше, спирт, күн аяк киемнәре, киез итек, тегү, кондитер, сыра кайнату промышленносты яңа баштан үзгәртеп корылдылар.

Татарстанда җир асты байлыклары гаять зур. Иске Тәкермәндә, Баржы-Умгада, Красный Борда ташкүмер чыганаклары табылды. Бакыр рудалары чыга торган аерым урыннар, сланецлар, ашламага эшкәртү өчен яраклы бик күп торф, фосфоритлар барлыгы беленде. Болар арасында флоредин балчыгы зур урын тота. Флоредин запаслары бездә 52 миллион кубометр күләмендә исәпләнә. Кама Тамагы районында цемент-ашлама һәм күкерт кислотасы эшләү өчен чимал бар.

Волга — Урал арасында яңа нефть базасы — „Икенче Баку“ төзү турында ВКП(б) ның XVIII нче съездының карары Татарстанга турыдан-туры кагыла. Нефть чыгару промышленностында аның үсеш перспективалары гаять зур.

Татарстан республикасы меридиан буенча да, киңлек буенча да нефть чыга торган гаять зур районның үзәгендә урнашкан. Элек-электән үк нефтьнең җир өстенә чыккалап торуы, шулай ук хәзерге геологик тикшеренүләр Татарстанда, һич шиксез, нефть барлыкны күрсәтәләр.

Куйбышев гидроузелы төзелү уңае белән су астында калачак урыннарда тикшерү эшләрен тизләтү турында иптәш Каганович приказ бирде. Шуннан соң, көнчыгыш Главнефтедобыча тресты Татарстан территориясендә нефть эзләү мәсьәләсе буенча безнең вәкилләр катнашы белән үткәрелгән махсус киңәшмәдә Татарстанда нефть эзләү эшләренә план төзеде.

Киңәшмәдә билгеләнгән эшләрнең күләме һәм темплары көнчыгышта „Икенче Баку“ төзү мәсьәләсе буенча ВКП(б) ның XVIII нче съездында кабул ителгән карарларга җавап бирәләр.

Татарстан территориясендә нефть эзләү эшен „Сызраньнефть“ тресты һәм баш Геология Идарәсенең Татарстан бүлеге алып бара.

Хәзер Булдырьда (Чистай шәһәре) ротор белән бораулауга хәзерлек тәмам булып килә.

Татарстандагы башка урыннарда ротор белән бораулау эшенә үткән ел 1 миллион 620 мең сум акча җибәрелде.

Үзебезнең ягулык базабызны булдыру халык хуҗалыгының өченче бишьеллык планының үзәк бурычларыннан берсе.

Безнең алга бу өлкәдә зур бурычлар килеп баса.

* * *

Ташкүмер чыгару эше Җирле Промышленность Халык Комиссариаты һәм промкооперация буенча Чыршылы һәм Иске-Тәкермән күмер чыганакларында үткәреләчәк.

Башка күмер чыганакларында (Чистай, Балык Бистәсе, Тәкәнеш) якын елларда промышленность өчен эшләүгә керешерлек итеп, күмернең катлауларын һәм аларның сыйфатын яхшы итеп тикшерү эшләре билгеләнде.

Торф запасы бездә 8 миллион 510 мең тонна исәпләнә (эрерәк чыганакларда). План буенча 1940 нчы елда 265 мең тонна торф чыгарылырга тиеш. Ә 1938 нче елда ул 80 мең тонна булды.

Бу—катлаулы, зур, ләкин реаль бурыч.

Җирле төзү материаллары производствосы Татарстанның халык хуҗалыгында тар урын булып тора.

Төзү материаллары хәзерләү буенча яшәп килүче предприятиеләренең производство көченнән тулы файдалану, аларны киңәйтү, үзгәртеп кору һәм яңа предприятиеләр төзү—халык хуҗалыгының якын еллардагы кичектерелмәслек бурычларыннан берсе.

Совнарком янындагы Төзү материаллары Идарәсе буенча кирпеч заводлары һәм цемент заводы төзү билгеләнде. Төзү индустриясе һәм төзү материаллары Наркоматы буенча Кама Тамагында цемент заводы төзү проектлаштырыла. Шуның өстенә, район башкарма комитетлары промышленносты буенча 12—16 кирпеч заводы төзү һәм Татпромсовет системасы буенча заводларны киңәйтү һәм яңа заводлар салу билгеләнә.

4 нче ясалма каучук, кинопленка, фото-желатин заводлары, резино-регенератор, ясалма күн заводларының һәм промышленностьның үткән елны төзелеп бетмәгән башка күп кенә предприятиеләренең төзелеп бетүе промышленность төзелешендә әһәмиятле урын тота. Шуның өстенә, күп кенә яңа предприятиеләр төзү билгеләнә. Алардан иң әһәмиятлеләре: авто-трактор детальләре һәм лак-буяу заводлары, копировальный һәм мамык фабрикалары, тегермән һәм кошчылык комбинатлары, икмәк заводлары һәм башкалар.

Район башкарма комитетлары промышленносты һәм промкооперация хезмәт ияләренең сорауларын канәгатьләндерү эшендә зур роль уйнарга тиешләр. Район башкарма комитетлары промышленносты һәм промкооперация буенча киң куллану әйберләре мастерскойлары: агач эшкәртү, чүлмәк әйберләр эшләү, тегү, трикотаж, металл әйберләр производствосы һәм башка күп кенә мастерскойлар оештыру күздә тотыла. Алар Татарстан республикасы районнарында урнаштырылачаклар. Өченче бишьеллыкта Татарстан халык хуҗалыгының һәм культурасының башка тармаклары да ныгырак алга китү өчен тагын да зур ярдәм алалар.

Татарстанның партияле һәм партиясез большевиклары алдында гаять зур бурычлар тора— „Без шулай эшләргә тиешбез ки, планның срогыннан элек үтәлүе белән дан алган беренче сталинчыл бишьеллыктан соң, һәм шундый ук уңыш белән тәмам ителгән икенче сталинчыл бишьеллыктан соң, без: өченче сталинчыл бишьеллыкны үтәү һәм арттырып үтәү өчен большевикларча көрәштек, без яңа, большевистик җиңүне тәэмин иттек, дип горурлык белән әйтә алырлык булсын, һәм шул вакытта өченче бишьеллык эштә ничек булырга тиеш булса, шулай булыр,—СССР дагы көчләрнең куәтле күтәрелешенең яңа бишьеллыгы, сталинчыл җиңүле бишьеллык булыр“ (Молотов).

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 7 гыйнвар. (ТАСС). Кичә кич иглан ителгән белдерүдә болай диелә: „Көн буена фронтның төрле участкыларында безнең патрульләрнең дошман белән бәрелешләре булды. Шул ук вакытта безнең тарафтан берничә кеше пленгә алынды".

Бүген иртә белән иглан ителгән белдерүдә болай диелә: „Фронтның төрле участкыларында патрульләрнең хәрәкәте булды. Блис елгасыннан көнчыгыштарак районда кич белән артиллериядән шактый көчле атыш барды".

БЕРЛИН, 7 гыйнвар. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Германия армиясе верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Көнбатыш фронтта әйтерлек бер нинди вакыйгалар булмады. Германия авиациясе Англия һәм Франция өстендә разведка очышлары ясады".

ЛОНДОН, 7 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгы 5 нче гыйнварда кич белән Англия самолетларының төньяк - көнбатыш Германия өстендә разведка очышы ясаганлыкларын хәбәр итә.

Англия - Америка мөнәсәбәтләре

НЬЮ-ЙОРК, 7 гыйнвар. (ТАСС). Ассошиэйтед пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, рәсми даирәләрдә Америка хөкүмәте тарафыннан Англиягә җибәрелгән протест ноталарының берсенә дә Англиянең шушы вакытка кадәр җавап бирмәвеннән ризасызлык белдерәләр. (Маглүм ки, Америка хөкүмәте Американың хокукларын Англиянең бозуына каршы протест йөзеннән 3 нота: Германия экспортына блокада ясавына каршы, Америка почтасын басып алуга каршы һәм Америка судноларын контроль портларга алып керүгә каршы ноталар биргән иде). Болардан тыш Англия 300 миллек нейтраль зонаны Англиянең бозуына каршы Америка илләре биргән протест нотасына да җавап бирмәгән иде. Юнайтед пресс агентлыгы „рәсми кешеләр арасында Америка пароходчылыгына Англиянең катнашуыннан ризасызлык үсүне" хәбәр итә.

АКШ ның Англиягә нотасы

ВАШИНГТОН, 7 гыйнвар. (ТАСС). 5 нче гыйнварда АКШ ның дәүләт департаменты 14 нче декабрьдә Англиягә тапшырган нотаның текстын иглан итте. Бу нотада Америка хөкүмәте, әгәр дә Америка суднолары Англиянең контроль портларына кертелеп аларга „зыян һәм зарар" китерелсә, моның өчен бөтен җаваплылыкны Англиягә йөкләячәген белдерә.

Шул ук вакытта дәүләт департаменты Американың Бергенга (Норвегия) бара торган „Мурмаксэн" пароходының 4 нче гыйнварда көчләп Англиянең Киркуэллдагы контроль портына китерелгәнлеген иглан итте. Берген нейтралитет турындагы закон буенча Америка судноларының керүе тыела торган зона исәбенә керми. Киркуэлл порты тыелган зона эченә керә. Шунлыктан дәүләт департаменты АКШ ның Лондондагы илчелегенә һәм Бергендагы консуллыгына пароходның бу тыелган зонага ничек кертелүе сәбәпләрен тикшерергә такдим итте.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кантоннан төньякта Кытай гаскәрләре инициативаны үз кулларында тоталар. Көньякка таба һөҗүмне дәвам иттереп, кытайлар бу районда японнарны берничә авылдан бәреп чыгардылар.

Гуандун провинциясенең көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Чаочжоу районында японнарга ныклы каршылык күрсәтәләр.

Кытай гаскәрләре Наньниннан көньяктарак күп кенә авылларны алдылар. Гуньлиньгуань тау юлы районында кытай гаскәрләре японнарның яшерен хәрби складларын таптылар. Складта 20 орудие, винтовкалар һәм 10 папка хәрби документлар калдырылган булган.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре отряды Наньчанга якынлашты.

Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә Синьян районында кытай гаскәрләре японнарны Дахуншаньнан бәреп чыгардылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә соңгы көннәрдә кытай гаскәрләре японнарның Юйсян районындагы позицияләренә атака алып баралар.

Хэбэй провинциясенең үзәк өлешендә декабрьнең соңгы 10 көнендә японнарның Танака дивизиясенең 4 мең чамасы кешесе үтерелгәнлеге һәм яраланганлыгы маглүм булды. Кытай гаскәрләре 51 пулемет һәм күп кенә сугыш кирәк-яраклары кулга төшергәннәр.

Кытайда яңа „үзәк хөкүмәт" төзү турында Домей Цусин агентлыгы

ТОКИО, 7 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин атентлыгы, Кытайның яңа „үзәк хөкүмәте" дип аталган хөкүмәтне төзү турында Япониянең Кытайдагы властьлары белән Ван Цзин-вей арасында килешүгә ирешелгәнлекне хәбәр итә. Ван Цзин-вей японнар куйган барлык таләпләрне кабул иткән.

„Джапан таймс" газетасы Япония таләпләренең характеры турында яза. Аның язуына караганда, кытайның Ван Цзин-вей җитәкчелегендәге „үзәк хөкүмәте" Япония белән дипломатия мөнәсәбәтләрен яңадан урнаштырырга, Япония белән Кытай арасында политик килешү төзергә һәм Япония белән экономик яктан бергә эш итү урнаштырырга тиеш.

НЬЮ-ЙОРК, 7 гыйнвар. (ТАСС). Японнарның Кытайда „үзәк хөкүмәт" төзергә маташуларына монда Япониянең Кытайда сугышның озакка сузылуы уңае белән кичерә торган кыенлыклардан чыгарга юл эзләве дип карыйлар. Японнар Ван Цзин-вейнең курчак хөкүмәте аларга Кытайның үзләре басып алган өлешендә ныгып калырга ярдәм итә һәм Япониянең хуҗалык организмын гадәттән тыш бөлгенлеккә төшергән сугышны шушы нигездә бетерергә мөмкинлек бирер дип ышаналар.

ЯПОНИЯ ПАРЛАМЕНТЫНДА ПОЛИТИК КАРШЫЛЫКЛАР

ТОКИО, 7 гыйнвар. (ТАСС). 26 нчы декабрьдә Япония парламентындагы түбәнге палата депутатларының шактый зур группасы тарафыннан Абэ кабинетына ышанмаучылык белдерү турында кабул ителгән резолюция хәзер Япониянең идарәче даирәләренең игътибар үзәгендә калуында дәвам итә. Хәзер оппозиция группасына 251 депутат, ягни түбәнге палата депутатларының яртыдан күбрәге керде.

„Джапан таймс" газетасы болай дип яза: „Баш министрнең барлык политик кыенлыкларны бетерергә тырышуына да карамастан, аңа моны тормышка ашыру кыен булачак. Политик даирәләрдә баш министргә кабинетны парламентның алдагы сессиясе аркылы үткәрү практик төстә мөмкин түгел дип саныйлар, чөнки парламент депутатлары арасында хөкүмәткә каршы настроение көчәйгәннән-көчәя бара".

ШВЕЦИЯ РЕАКЦИЯСЕНЕҢ ПРОВОКАЦИЯСЕ

СТОКҺОЛЬМ, 7 гыйнвар. (ТАСС). Коммунистлар партиясенә һәм эшчеләрнең оешмаларына каршы матбугатта озак кампания алып барганнан соң, Швеция реакциясе тагын да көчлерәк средстволарга күчте. Бүген төнлә Швеция коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты һәм „Ню даг" редакциясе урнашкан бинаның ишек алдында бомба шартлады. Шартлаудан зыян килмәде.

Швеция реакциясенең бу чираттагы провокациясен Швеция матбугаты „шартлату хәзерләүдә" коммунистларны гаепләү өчен сылтау итеп файдаланырга маташа.

Англиядә туклану продуктларына карточка системасы

ЛОНДОН, 7 гыйнвар. (ТАСС). Англиянең информация министрлеге 8 нче гыйнвардан башлап Англиядә майга, беконга, дуңгыз итенә һәм шикәргә карточка системасы кертелә башлауны хәбәр итә. Карточка буенча ит 1914—18 нче еллардагы бөтен дөнья сугышы вактындагы күләмнәрдә бүленәчәк.

Япония кабинеты балык тоту турында Япония белән СССР арасында төзелгән килешүне яхшы дип тапты

ТОКИО, 7 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы, балык тоту турында Япония белән СССР арасында 1940 нчы елга төзелгән килешүнең 6 нчы гыйнварда кабинетның чираттан тыш утырышында расланганлыгын хәбәр итә. Килешү протоколы ратификацияләү өчен яшрен советка тапшырылачак.

СОВЕТ—БОЛГАРИЯ СӘҮДӘ ДОГОВОРЫ ТУРЫНДА БОЛГАРИЯ МАТБУГАТЫ

СОФИЯ, 7 гыйнвар. (ТАСС). Кичә барлык газеталар СССР белән Болгария арасында сәүдә һәм диңгездә йөзү турындагы договорга кул куелуны һәм бу договорның төп эчтәлеген үзләренең беренче битләрендә басып чыгардылар. Газеталар товар әйләнешенең договорда күздә тотылган гаят зур күләмен аеруча күрсәтеп үтәләр. „Вечерь" газетасы „Болгария өчен дә, шулай ук СССР өчен дә гаят файдалы булган бу договорны ике илнең дә җамагатчелек фикре зур канәгатләнү белән каршы алды" дип яза.

МАРТИН АНДЕРСЕН-НЕКСЕ КИТАБЫН ЭЗӘРЛЕКЛӘҮ

СТОКҺОЛЬМ, 7 гыйнвар. (ТАСС). Мартин Андерсен-Нексенең „Финляндия—политик террор иле" исемле китабын Швеция властьлары тыю теләге белән юстиция министрлегенә тапшырганнар.

БРАУДЕР — ВӘКИЛЛӘР ПАЛАТАСЫ ЧЛЕНЛЫГЫНА КАНДИДАТ

НЬЮ-ЙОРК, 7 гыйнвар. (ТАСС). Америкада чыга торган „Дейли Уоркер" газетасының хәбәр итүенә караганда, Браудер Нью-Йорктагы сайлауларда вәкилләр палатасының бушаган урнына Компартиянең кандидаты итеп күрсәтелгән.

ФИЛИППИНДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ЭШЧЕЛӘРЕНЕҢ ЗАБАСТОВКАСЫ

НЬЮ-ЙОРК, 7 гыйнвар. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Филиппиндагы 20 мең авыл хуҗалыгы эшчесе хезмәт хакын арттыруны һәм шикәр компанияләре янында полицияне бетерүне таләп итеп забастовка иглан иткәннәр.



Сталин исемендәге ФЗУ мәктәбе (Казан) югары квалификацияле токарьлар һәм слесарьлар хәзерли. РӘСЕМДӘ: инструктор Н. Бадыгов (сулдан) яш токарь, уку отличнигы М. Заһидуллинга инструктаж бирә.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ИЛЕБЕЗ ЧАКЫРСА

Арысланнар менмәс зур таулардан,
Кошлар җитмәс комлы далалардан,
Чабып үтәрбез.
Илебез чакырса,
Явыз дошманнарны
Көлдәй итәрбез.

Үтә алмаслык куе урманнардан,
Күз ачмаслык көчле бураннардан,
Кыю чыгарбыз!
Явыз дошманны,
Үз җирләрендә
Тотып кыйнарбыз.

Шаулы диңгез, океан дулкыннарын
Һәм Котыпның калын күк бозларын,
Ярып үтәрбез.
Илебез чакырса
Барлык дошманнарны,
Без юк итәрбез!

Зур гигантлар үскән калалардан,
Алма, чия пешкән авыллардан
Күтәрелербез.
Илебез чакырса,
Каты сугышларга,
Җырлап үтәрбез!

Типсә тимер өзәрдәй егетләр,
Чапаев һәм Буденный кебекләр,
Менеп атларга,
Илне сакларга,
Тыгыз сафларда,
Китәрбез алга.

Сакаллары агарган картлар да,
Туган илем сораган чакларда,
Ялкындай үтәр.
Барлык дошманны,
Һавада, җирдә
Океан, диңгездә
Мәңге юк итәр!

Без керербез шашкын ялкыннарга,
Һәм дәһшәтле ташкын упкыннарга,
Чакырса илебез.
Бар көчебезне,
Гомеребезне,
Аңа бирербез.

Кызганмыйбыз һич тә үзебезне,
Саклар өчен туган җиребезне
Илебез чакырса.
Сафка басарбыз,
Явыз дошманның
Барын сытарбыз.

Макс Гатау.

КОЛХОЗ-СОВХОЗ ТЕАТРЫНЫҢ КАДРЛАРЫ

Мамадыш районындагы 2 нче номерлы колхоз-совхоз театры моннан 5 ел элек оештырылган иде. Кечкенә драма түгәрәгеннән оештырылган бу театр үз эшенең беренче көннәрендә бер-ике пәрдәлек пьесалар белән райондагы колхозларга хезмәт күрсәтте.

Үткән 5 ел эчендә театр зур уңышларга иреште. Ул хәзер зур пьесалар, классик әсәрләр куя алырлык һәм күп кенә районнарга хезмәт күрсәтүче театр булып әверелде.

Артистка Шәйхеттинова халык арасында урынлы мактала. Ул образлар тудыруда тырышып эшләү белән бергә, җырларны башкаруда да күренекле уңышларга иреште. Иптәш Абдрахманов гади артисттан режиссер итеп күтәрелде. Иптәш Катеев хәзерге вакытта театрның директоры булып эшли. Театрның элекке директоры иптәш Альханов Татар Дәүләт Академия театрының директоры итеп күтәрелде.

Составның күпчелеге театр оештырылган көннәрдән бирле эшләп килә. Һәм алар, шушы вакыт эчендә, массаның культура таләпләренә җавап бирә алырлык дәрәҗәгә үстеләр. Алар үзләренең квалификацияләрен күтәрү белән бергә, большевизмны үзләштерү өстендә дә тырышып эшлиләр. Артистлар арасыннан 15 кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнә.

Театрның комсомол оешмасы артистлар арасында политик-тәрбия эшләрен соңгы вакытларда күп яхшыртты. Артистлардан Досаев, Садрина, Гайфуллина иптәшләр ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алындылар.

Театр үз алдына куелган бурычны уңышлы үтәп бара. 1939 нчы елда театр 185 постановка бирде һәм аларны 50 меңнән артык кеше карады. Театр колхозларда булганда постановкалар белән генә чикләнми, колхозчылар арасында политик-агитация эшләрен дә киң оештыра. Театр янында агит-коллектив эшли.

Театрның шушы вакыт эчендә ирешкән уңышлары, һич шиксез, зур. Ләкин бу, моның белән тынычланырга кирәк дигән сүз түгел. Алда гаять зур бурычлар торалар һәм театр коллективы үзенең бөтен көчен шушы бурычларны уңышлы хәл итү эшенә тупларга тиеш. *Г. Мостафин.*

М. ГАФУРИ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯҢА ҖЫЕНТЫГЫ

Татгосиздатның художество әдәбияты секторы Мәҗит Гафуриның моңа кадәр бер кайда да басылмаган әсәрләренең зур җыентыгын басарга хәзерли. Җыентыкка шагыйрьнең лирик шигырьләре һәм зур күләмле проза әсәрләре кертелде. Җыентыкка кергән әсәрләр арасында әдәби яктан яхшы эшләнгән „Минем тәрҗемәи халем", „Баштан узганнар", „Г. Тукай Уфада" һәм язылып бетмәгән „Бер мәхәббәтнең тарихы" шикелле мемуар характерындагы әсәрләр бар.

Җыентык иллюстрация белән чыгарыла. Ул шагыйрьнең иҗадын өйрәнүдә кыйммәтле материал булып торачак. М. Гафури әсәрләре җыентыгы 1940 нчы елның беренче яртысында басылып чыгачак.

АЛДЫНГЫ ПОЖАРНЫЙНЫ БҮЛӘКЛӘҮ

Социалистик милекне пожар куркынычыннан саклаган вакытта геройлык һәм батырлык күрсәтүе, шулай ук кешеләрне янган ут эченнән коткаруы өчен ССР Союзы Эчке Эшләр Халык Комиссариаты пожарный Борһан иптәш Нәҗмиевне „Пожар сакчылыгының иң яхшы работнигына" дигән значок белән бүләкләде.

Иптәш Нәҗмиев Казан шәһәрендәге беренче пожар командасының иң алдынгы сугышчыларыннан санала.

Карт шахтерлар үрнәк күрсәтәләр

Донбасс. Макеевка районының „София" күмер шахтасында иптәш Якупов Ислам 37 ел эшли. Аның бай тәҗрибәсен күпләр өйрәнәләр. Иптәш Якупов планны ай саен арттырып үти.

39 ел стажлы карт шахтер иптәш Мифтахеттинов та айлык планны һәр вакыт 180—250 процент итеп үти. Ул яш эшчеләрне дә эшкә өйрәтә. *Г. Камалов.*

5.261 МЕҢ КУБОМЕТР СУ

1939 нчы елда Казан шәһәре водопроводы 1858 абонентка 5.261 мең кубометр су бирде. Хәзер водопровод челтәренә тагын яңа йортлар өстәлде. Коммунальниклар, киез итек фабрикасының торак йорты, Мехкомбинатның яслесе, Калуга тавындагы мәктәп һәм башка йортларга водопровод кертелде.

Быел трубаларда суның басымын арттыру буенча күп кенә эшләр үткәрү билгеләнә. Волга водопроводы магистрале шәһәр водопровод челтәре белән тоташтырылачак.

Волга водопроводы төзелешендә баш водоводны төзеп бетерү билгеләнә. Фильтр станциясен төзеп бетергәннән соң шәһәргә Волгадан су җибәреләчәк.

УРМАН КИСҮЧЕЛӘР ӨЧЕН МӘКТӘП

Чаллы районының Кызыл Тавыс урманчылыгы янында урман кисүчеләрнең квалификацияләрен күтәрү буенча мәктәп ачылды. Мәктәптә 20 кеше укый. Алар, СССР да атаклы урман кисүчеләрдән Гузиенко һәм Готиннәрнең эш методларын өйрәнәләр. Иң яхшы бригадаларның эш йомгакларын тикшерәләр.

Хезмәтнең бу яңа методы пунктның урман кисүчеләре тарафыннан тиз һәм яхшы үзләштерелә. Алар, эш көчләрен дөрес урнаштыру, яңа метод белән эшләү нәтиҗәсендә шактый уңышларга ирешәләр. Мәсәлән, иптәш Кучин бригадасы уртача көнгә 2 норма һәм аннан да күбрәк эшли. Хәзер урман кисүчеләр айга 750—900 сум хезмәт хакы алалар.

КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

— Тәкәнеш Райпотребсоюзы 1939 нчы елда район күләмендә 5 яңа магазин, 4 ашханә, 4 ларек һәм 3 чәйханә ачты.

— 2 нче гыйнварда Биектау районында Дәүләт банкасының район бүлекчәсе ачылды. Моңарчы Биектау районына Казан Дәүләт Банкасының конторасы хезмәт күрсәтә иде.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КАЗАН ПРОМЫШЛЕННЫЙ БАНК ТЕХНИКУМЫ
1 нче КУРСКА УКУЧЫЛАР АЛА
Техникум төзелешләргә акча җибәрү һәм контрольлек итү эшләре буенча кредит — инспекторлары хәзерли —
УКУ СРОГЫ—3 ел.

Техникумга 15 тән 30 га кадәр яшьтә булган һәм тулы булмаган урта (7 еллык) мәктәпне төгәлләгән барлык гражданнар алыналар.

Техникумга керүчеләр шушы ел 20 нче гыйнвардан 1 нче февральгә кадәр, тулы булмаган урта мәктәп программасы күләмендә рус теленнән һәм әдәбиятыннан, математикадан (арифметика, алгебра һәм геометрия), географиядән һәм СССР Конституциясеннән сынаулар үтәләр.

Тулы булмаган урта мәктәпне төп предметлар буенча отлично билгесе белән төгәлләүчеләр техникумга сынаусыз алыналар. Укулар шушы ел 1 нче февральдә башлана.

Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, яше һәм тулы булмаган урта мәктәпне төгәлләү турында документлар, сәламәтлеге турында медицина белешмәсе, һәрберсенә керүченең имзасы куелган һәм дәүләт учреждениесе тарафыннан расланган ике данә фотокарточка бирелергә тиеш.

Гаризалар шушы ел 20 нче гыйнварга кадәр алына.

Техникумга алынганнарга гомуми нигездә стипендия һәм тулай торакта урын бирелә.
Казан, Карл Маркс урамы, 43. Промбанк техникумы. 27—3—1

19 нчы гыйнвар, кич 5 сәгатьтә Казан Дәүләт Зооветеринария институтының актовый залында институт гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм ветеринария фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен түбәндәге темаларда — халык алдында —
ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ
үткәрелә:

1. Саратов Зооветеринария институтында доцент хезмәтләрен үтәүче Е. А. Покровская. Тема: „Бозауларга эчерү өчен гигиена әһәмиятен бәяләү ягыннан молозивның составы һәм сыйфаты".

Рәсми оппонентлар. профессор доктор С. Н. Афонский һәм профессор доктор П. Я. Сырнев.

2. Казан Дәүләт Зооветеринария институты ассистенты Ф. Ф. Федотов. Тема: „Татарстан АССР ның төньяк-көнчыгыш зонасында җирле терлекләрне швиц нәселле терлекләр белән метизлаштыру".

Рәсми оппонентлар: профессор доктор П. Я. Сырнев һәм ветеринария фәннәре кандидаты доцент А. М. Барсков.

Диссертация материаллары белән институт китапханәсендә танышырга мөмкин.
33—1

Игтибар итегез!
Главмясосбыт Татарстан конторасы — карамагындагы —
ЗАКУСОЧНАЯ
иттән хәзерләнгән һәр төрле порцияле кайнар ашлар, шулай ук, кубәйтелгән порцияле ПИЛЬМӘННӘР һәм СОЛЯНКАЛАР хәзерли. Килүчеләргә хезмәт күрсәтүдән тыш, ашлар чикләнмәгән күләмдә өйгә дә җибәрелә. Ашлар югары сыйфатлы продукциядән хәзерләнә һәм бәяләре дә югары түгел.
Адрес: Бауман урамы, 33.
2495—3—1

Татреспторг 50—60 ат көчле мотор куелган
КАТЕР
(керосин белән эшли торган булуы яхшырак) һәм 100 тонна йөк күтәрешле
ИКЕ БАРЖА САТЫП АЛА.
Казан, Бауман урамы. 52-7, өченче кат. Телефон 17—13.
2638—2—1—а

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген һәм иртәгә театрның ял көннәре.
11 нче гыйнварда
КАЧКЫН
операсы
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 9 нчы гыйнварда көндез һәм кич, шулай ук иртәгә
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Көндез талоннар белән кертелми. Кич—72.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.
КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ
12 нче гыйнварда көндезге спектакльгә коллектив заявкалар буенча килүчеләргә (100 билеттан ким булмаганда) 50 процент ташлама ясала.

КИРӘК:

Сельхозснабның Казан базасына даими эшкә ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕРЛАР һәм КАРТОТЕКАЧЫЛАР. Казан, Володарский урамы, 8. Баш бухгалтерга мөрәҗәгат итәргә. 25—2—2

Главлегснабның Казан конторасына СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, химикатлар хәзерләү буенча ТОВАР БЕЛГЕЧЕ һәм өстәмә хезмәт рәвешендә эшләү өчен ЮРИСКОНСУЛЬТ. Көндезге 4 сәгатьтән 5 кә кадәр Главлегснабка килергә. Казан, Кече Ямашев урамы, 71. 4—2—2

С. М. Киров исемендәге Казан Химико-Технология институтына МАШИНИСТКАЛАР, СЛЕСАРЬЛАР, ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, КОЧЕГАРЛАР һәм ПОДКИДЧИКЛАР, КИЕМ ЭЛГЕЧЕНДӘ ЭШЛӘҮЧЕЛӘР, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, автомашиналарда эшләү өчен грузчиклар, ПЫЯЛА КАБАРТУЧЫЛАР, укыту бүлеге өчен СЕКРЕТАРЬ, реактивлар һәм җиһазлар җитештерү буенча ИНЖЕНЕР - ХИМИК, ТӘҖРИБӘЛЕ СТЕНОГРАФИСТКА һәм институт китапханәсенең чит телләр бүлегендә эшләү өчен, ЧИТ ТЕЛЛӘРНЕ БЕЛҮЧЕ РАБОТНИК. 35—3—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының — гастрольләре —
ЯҢА ЕЛ КАРНАВАЛЫ
Бөтен труппа катнаша.
12 нче гыйнварга кадәр һәр көн 11 сәгатьтә, 2 сәгать 30 минутта һәм кич 8 дә
— ЦИРК УЕННАРЫ —
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 11-45, 1-45, 3-45, 5-45, 7-45 һәм 9-45 тә.	Көндез 10 сәгатьтә ҺАВА ПОЧТАСЫ һәм башка сеансларда УКЫТУЧЫ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ Көндез 10 сәгатьтә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда ФЕДЬКА Кич УКЫТУЧЫ
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„ПИОНЕР" 11, 2, 4, 5-45 8, һәм 10-15 тә	Көндезге сеансларда ПАРТИЗАН КЫЗЫ Кичке сеансларда БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе) Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс
„ЮТ-ФРОНТ" 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	Бөек бүләк
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	Укытучы

„Рационализатор" атлы заводы директоры Николай Ефремович Коренович исеменә Татарстан АССР Наркомлесыннан 1939 нчы ел, 9 нчы декабрьдә бирелгән 13—20 номерлы ышаныч кәгазен гамәлдән чыккан дип санарга. 36—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 204 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА ДОМ ПЕЧАТИ: 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 108.